Фәйрүзә Мөслимова

# Алтын йозак

Шигырьләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2009

УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2 Рос=Тат)-5
М96

**Мөслимова, Ф.Ә.**

М96 Алтын йозак : шигырьләр / Фәйрүзә Мөслимова. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2009. – 192 б.
ISBN 978-5-298-01835-7

Шагыйрәнең әлеге китабына соңгы елларда иҗат ителгән нечкә лирик-фәлсәфи шигырьләре тупланды.

УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01835-7
© Татарстан китап нәшрияты, 2009
© Мөслимова Ф.Ә., 2009

# *I. Гомер – диңгез, төсләр уйный...*

## ФЕНИКС

Янам-янам да кабат яралам
Көлдән яралган Феникс кебек.
Күтәрелмәкче булам һавага,
Каурыйларыма ярамны төреп.

«И юләр кошкай, әкият бит ул
Кабат яралу, терелү кабат...» –
Кемдер шулай дип эндәште бугай,
Мин узган юллар-елларны санап.

Искә төшермә, дәшмә, ят тавыш,
Бу хакта инде мин беләм күптән.
Аһ, мин нинди карт, борынгы, диеп,
Япь-яшь көннәрем, гомерем үткән.

Янам-янам да кабат яралам,
Ә бер көн килер – ярала алмам?
– Гомерләр узган, картайганмын, – дип,
Бүтән беркайчан инде зарланмам?

Исән чагында гөнаһ түгелдер
Көлдән яралу Феникс сыман.
Яраларымны канатым каплар,
Күз яшьләремне яңгырлар юар...

## АЛТЫН ЙОЗАК

Тыңлаучылар кирәк безгә –
Аңлаучылар серебезне.
Аударасы килә тизрәк
Җанны кыйган йөгебезне.

Сөйләүчеләр күбрәк хәзер,
Тыңлаучылар кадерлерәк.
Канатланып китәр өчен
Бушанырга әзер йөрәк.

Сер сыйдыру – сәнгатьтер ул,
Тыңлаучыны таптык инде.
Серебезне ачу белән
Алтын биккә яптык инде.

Җиде күккә күтәрелдек.
Кул изәде җирдән безгә!
Аның гына... үз хәлләрен
Сорашмады беребез дә...

## КЫРМЫСКА

Җир йөзенә кояш чыга, кояш байый,
Җир йөзенә яңгыр ява – сулар таша.
Шул дөньяда һәрбер кеше кырмыскадай
Үз саламын сөйрәп бара еллар аша.

Ходай биргән язмышыңны каргамассың,
Йөк өстерәү рәхәт түгел түгелен дә.
Кырмысканы кем уздырыр чыдамлыкта? –
Сөйри генә авырын да, җиңелен дә.

Йөргән булам мин дә шулай салам сөйрәп,
(Бу дөньяга без эшлексез яралмаган!)
Бетми генә! Югыйсә бит әллә кайчан
Эскерт үсте без ташыган саламнардан.

## ГАМЬ

Күзләремне иңләп кошлар оча,
Шәүләләре төшә тәрәзәгә.
Кош канаты сыйпап үткән саен,
Тәрәзәмдә күкләр зәңгәрләнә.

Кош канаты сыйпап үткән саен
Күзләр белән офык араларын,
Гамьнәремне киң галәмгә биреп,
Йөрәгемә җыям яңаларын.

Бу галәмдә мин дә бер кош бугай,
Дөнья гамен канатыма салыйм!
Күкләр генә зәңгәрләнсен иде,
Канатларым сыйпап үткән саен.

## САГЫНАМ, ДИСЕҢ...

*Мөдәррис Әгъләмовка*

Киттем исә, сагынам, дисең,
Әллә чынлап, әллә көлеп,
Мин югында сезгә, дисең,
Әллә ниләр булган кебек.

«Әллә ниләр булган сыман,
Әйләнәм дә тагын киләм:
Барысы да әйбәт икән,
Хәлләрегез менә дигән».

Хәлләребез менә дигән.
Сиңа нидер булган кебек,
Эчләребез поша безнең,
Күренмәсәң үзең килеп.

Күренмәсәң, күренсәң дә,
Әллә ниләр булып тора.
Сезнең гомер, безнең гомер
Шуның белән тулып тора.

Гомер дә бит узып бара,
Чынлап кына, уйнап-көлеп.
Яшәвебез үзе әле –
Әллә ниләр булган кебек.

## КИТӘЛӘР...

Китәләр кояшлы юллардан –
Җаныма якыннар китәләр.
Өметме, бәхетме йөртәдер?
Тик мине ник ялгыз итәләр?

Китәләр яңгырлы юллардан –
Болытлы күлләрне кичәләр.
Күңелдә кала тик яктырып
Бергәләп үткәргән кичәләр.

Китәләр бураннар артыннан –
Елларны йөгереп үтәләр.
Тынгылык эзләгән җаннарын
Ник моңлы, ник ялгыз итәләр?

Кешене өметләр яшәтә,
Уемда – күрешер иртәләр...
Нигә соң һаман да югалтам?
Нигә соң китәләр, китәләр?

## АГЫМСУЛАР БОЛГАНА

Болгана агымсулар да,
Ләм утыра ярларга.
Чумсалар да, йөзсәләр дә,
Кер дә кунмый казларга.

Күлләрдә дә дулкын уйный,
Дулкын уйный да тына.
Тап ясамый, эз дә салмый
Казларның канатына.

Каз канаты, каз канаты
Кагына да агара.
Нигә соң без, нигә соң без
Охшамаган казларга?

Без коенган сулар көмеш,
Чүп тә кунмый аларга.
Тик алай да безнең каурый,
Безнең канат карала.

... Зәңгәр күлдә дулкын уйный,
Агымсулар болгана.
Казлар кагынганга карап,
Күңелләрем моңлана.

## ДИҢГЕЗ

Ничек керми калмак кирәк –
Чакырса диңгез әгәр?
Айкалдым бер, чайкалдым бер –
Дулкыннар зәңгәр, зәңгәр.

Айкый дулкын, чайкый дулкын.
Чиксез суның юк яры.
Шул микәнни адашулар?
Ә диңгез сары, сары...

Нинди бетмәс чайкалу бу?
Хәлләрем китеп бара.
Үкенмәм кебек батсам да,
Ә диңгез кара, кара...

Караны ярып урталай,
Күкләрдә уйный яшен.
Бәлки, ярга юл табармын?
Ә диңгез яшел, яшел...

Гомер – диңгез, төсләр уйный...
Ниләр көтә тын ярда?
Калып булмый, җитеп булмый,
Йөзмичә дә юк чара.

## ҺӘР ИКЕНЕҢ БЕРСЕ...

– Һәр икенең берсе шигырь яза,
Шигырь белән дөнья туп-тулы.
Эч пошырып, каләм тоткан булып,
Син сырлама шигырь, һичьюгы!

– Һәр икенең берсе шигырь яза,
Шигырьченең сайдыр акылы:
Күпме вакыт шигыренә китә –
Җитди эшләр көткән аркылы!

– Һәр икенең берсе шигырь яза,
Шуның белән яулый игътибар.
Шигырьләре илгә чыгармаса,
Чүп тә түгел үзе, ихтимал!..

– Һәр икенең берсе шигырь яза, –
Дип үртиләр колак төбемдә.
Һәр икенең берсе... язсын, язсын! –
Белеп торам ансын үзем дә.

Илем-көнем, уем-хыялларым
Мәшәкатьләр белән туп-тулы.
Таянычым булган шигырьләрдән
Көнләмәгез мине, һичьюгы.

## БЕЗНЕҢ ҖЫР!

Әй сөйләде шагыйрь канатланып,
Әй дуслары сөеп алкышлады!
Сорап куйды бер гүзәлкәй шунда:
– Бу җырыгыз кемгә багышланды?

Каушатсалар, каушый шагыйрьләр дә,
Сөйли алмас инде канатланып.
Ә гүзәлкәй һаман: «Кемгә?» – диде,
Каушамыйча шулай кабатлады.

Эндәшмәде шагыйрь, башын иде,
Саксыз сорау саташтырды тәмам.
Аның күзләренә йотылды да
Тынып калды тамашачы гавам.

Соравыңны кире алчы, чибәр,
Шагыйрь чәчмәс йөрәк серен ваклап.
Ә шигыре безнең җыр бит хәзер,
Менә шушы минутлардан башлап!

## КАНУННАР...

Хыянәтчене терәп атарга –
Нинди кануннар яшәгән элек!
Хыянәттән зур җинаять югын
Торганнар белеп, торганнар белеп...

Хыянәтчегә хөкем юк хәзер.
Монысы гына җинаять түгел.
Арттан аталар хыянәтчеләр –
Шундый кануннар яшиләр бүген.

## ДОГА

Йолыгыз мине гөнаһтан,
Гөнаһсыз шигырьләрем.
Бу – минем ихлас йөрәктән
Соравым, гозерләвем.

Сәҗдәгә киткән шикелле
Тезләнәм кәгаземә.
Тик ул гына төшенә күк
Сагышым сәбәбенә.

И минем моңдаш шигырьләр,
Бар серем сездә генә.
Яшәү йөге авыр, авыр...
Кәгазем түзә менә.

Безнең гомер – чиксезлектә
Сызылып үтү генә...
Ак кәгазем, киткән чакта,
Үткәнгә үкендермә.

Бу минем – китеп сәҗдәгә,
Ихластан гозерләвем:
Аралагыз гөнаһлардан,
Гөнаһсыз шигырьләрем!..

## ШАГЫЙРЬ

Берьялгызын япан-яланнарда
Яман җилләр йолкып-йолкып узган...
Башкаларга охшамаган шул ул,
Яшәгәнгә сәер дәрвиш сыман.

Сызгырса да җилеп сәмум җиле,
Сәерлеген аның сындырмаган.
«Утыр безнең арбабызга», – диеп,
Кемнәр генә чакрып кул сузмаган.

Юк, аңарга түгел, башкаларга
Үзеннән гел ярдәм тиеп торган.
Япан кырда куе ябалдашлы
Имән кебек мәгърур, биек торган.

Көлә белми көлгәннәр дә әле:
Пәйгамбәре безнең замананың!..
Ялгыз калып сыктагандыр, бәлки,
Ишетмәгән һичкем зарланганын.

Мал-мөлкәт һәм дан-дәрәҗә өчен
Җан талашып яткан бу заманда,
Бүтәннәрдән үзгә – әрни-әрни
Бәгыре кайный шунда – бер казанда.

Мәңгелектән татлы ялган даулап,
Меңәрләгән мизгел-гомер уза.
Дан-дәрәҗә кирәк... Сискәник бер:
Дәрвиш җаны әнә ничек туза!

Могҗизадыр, бәлки: якты биреп,
Кызганмыйча үзен, дөрләп яна.
Аның саен һаман яшәрә дә
Югарыга гына үрләп бара.

## КАПКА ХИКӘЯТЕ

Илләр гизгән яшь егетне,
Юллардан арган чакта,
Канатларын коштай җилпеп,
Чакырды зәңгәр капка.

Илләр гизгән яшь егетнең
Килмәде сер бирәсе,
Офыклар дәшкән чагында
Капкага сөртенәсе.

Таң капкасы нинди алсу,
Ничек шунда җитәсе?..
Тик ансының, кер монда дип,
Юктыр, юктыр көтәсе.

Офыкларга буй җитәрме?
Яңадан кайткан чакта –
Хыялына фида җанны
Кемнәр көтәр бу якта?

Илләр гизгән горур затның
Килер башын иясе.
Зәңгәр капка ачылмас шул,
Күтәрелмәс келәсе...

## ТАБЫШМАК

Әйтерсең лә миннән калмый
Бер кечкенә кеше йөри:
Барысын да белеп тора,
Үзен генә һичкем күрми.

Яхшыга да, яманга да –
Бәя бирә һәр эшемә.
Дөнья-мәхшәр алдый алмас,
Тигезләнсәм шул «кеше»гә.

Бик югары йә бик түбән
Тәгәрәүдән саклый мине,
Кимсетергә теләүчедән
Хыянәтсез яклый мине.

Җилгә каршы бара-бара
Арып талсам, хәлем китсә –
Үз-үземә тугры булып
Калырга да ярдәм итә.

Бер кыйбладан икенчегә
Сикермәсен, ди ул, ялгыш.
Юл сабучым һәм киңәшчем
Ул «кеше» бит – минем намус!

## САУ БУЛЫГЫЗ, КИТӘМ...

Сикерә дә чыга, әрсезләнеп, телем.
Шул телемне җыйсам, әйбәт яшәр идем.

Дәшмәм дигәнем бар, әйтмәм дигәнем бар,
Телләремне тешләп, башым игәнем бар.

Дәшми калу – рәхәт, сүзсез тору – рәхәт.
Түзеп булса икән шулай рәхәт яшәп.

Күбрәк күрелә шул, ишетелә күбрәк,
Күкрәгемә сыймый бәргәләнә йөрәк.

Пырдымсызмы үзем, каян алыйм түзем?
Әйләнә дә кайта әйтмәм дигән сүзем.

Инде вәгъдә итәм: алай итмәм бүтән.
Үз-үземне алдап, үз-үземнән китәм!

Китәм, китәм!
...Йөз меңенче кабат: алай итмәм бүтән!

## ЯҢА ЕЛ ҖЫРЫ

Җәй гөлләре кар астында йоклый,
Боз тозакта – якты чишмә җыры.
Ак буранда адашкан чак була –
Бер тәрәзә җылы кирәк, җылы!

Бәсле куакларны кошлар сарган.
Миләшләрдә учак кызыллыгы.
Туңган кошны терелтергә хәтта
Тик бер тәлгәш җылы кирәк, җылы!

Кышлар арты язлар килә тора.
Каршы алган саен Яңа елны –
Өметебез исән калсын өчен,
Тик бер күңел җылы табыйк, җылы!

Безнең янда туңучылар юкмы?
Сүрелмиме күзләренең нуры?
Һәр Яңа ел якты булсын өчен,
Җаннар тулы җылы кирәк, җылы!

## КАБАТЛАНМАС...

Еллар арты еллар үтеп китәр,
Язлар белән ел да кар эрер.
Чәчкә төшкән бәсләр эремәсләр,
Үткәнгә тик хәтер җан өрер.

Еллар кары бер дә кабатланмас,
Яуган саен явар яңасы.
«Гомер зая, зая!» – дип, җан сыкрар,
Яшь чакларда килер каласы.

Яңа елның карлы бер төнендә
Алдыңда шәм сүнәр калтырап.
«Ул яратты! – диеп сискәнерсең, –
Ул көннәргә хәзер, аһ, ерак!»

Еллар кары әмма кабатланмас,
Тергезсәң дә кабат шәм утын...
Нәрсә сөйлим? Ашыга күр берүк –
Зая итмә шушы минутың!

Еллар кары кабатланмас бүтән...

## КЫШКЫ ТӘРӘЗӘЛӘР

Моңсу агачларны бәсләр сарган,
Кар шыгырдый аяк астында.
Якты тәрәзәләр, күзен кысып,
Җылынырга өйгә чакыра.

Чакырсалар әгәр тәрәзәләр,
Эчләрендә җәйләр бар сыман.
Карлы урамнарга чыккан саен,
Җылы тәрәзләргә тартылам.

Бар дөньяга җитәр ямьнәр бардыр –
Пәрдәләре бары каплаган.
Күңел кышларымнан йөгереп үтеп,
Җылы тәрәзләргә капланам.

Кар шыгырдый аяк асларында,
Йә сызгырып сара бураннар.
Тәрәзәләр җылыталар җанны,
Салкынайган саен урамнар.

## КЕШЕЛӘР

– Дөньялыкта күрешергә язсын,
Күрешергә язсын, – дисез дә
Тараласыз язмыш җиле белән
Дөньяларның төрле читенә.

Дөньялыкта күрешергә язсын...
Ә дөньясы бер кыл өстендә.
Тик күрешү өмет итә күңел –
Күп кирәкме җирдә кешегә?

Дөньялыкта күрешергә язсын...
Ә дөньясы никтер күпсенә:
Еллар, юллар ерагая бара,
Мәшәкатьләр – өсте-өстенә.

Дөньялыкта имин тормыш теләп
Калган олан-оныкъ өчен дә
Мәңгелеккә беркөн китәсез сез...
Сабырлыклар бирсен кешегә.

Һәрбер гомер – мизгел генә бары...
Дөньясы да тик кыл өстендә.
Ә сез һаман, һаман таралсыз,
– Күрешергә язсын, – дисез дә...

## КӨМЕШ ТӘҢКӘ

Син алтыннан кадерлерәк,
Көмеш тәңкә, көмеш тәңкә.
Чулпы итеп таккан сине
Чәчләренә минем әбкәм.

Хәсрәтләрен эчкә йоткан,
Сөенечтән көлеп йөргән.
Чулпы җыры итеп барсын,
Толымына көйләп үргән.

Бишек җыры җырлагансың
Әбекәмнең улларына...
Көмеш моңнар ишетәмен,
Алсам сине кулларыма.

Әбекәмнең истәлеге,
Балачагым төсе – тәңкә –
Колагалка ясап кидем,
Күз яшемне сөртә-сөртә.

Чулпы сыман челтеридер
Колагымда көмеш бизәк,
Көмеш алкам, көмеш алкам
Алтыныннан кадерлерәк.

## ОСТА

Кулларыннан гөлләр кояр,
Күңеленнән нур сибәр –
Сандыгын ясап куюга,
Килеп алыр бер чибәр.

Оста ясаган сандыкның
Бизәге челтәр-челтәр.
Көн килер дә бер чибәрне
Иң бәхетле яр итәр.

Уйнап кына торыр аның
Көянтәсе иңендә.
Сокланып туймас ил күзе
Яңа төшкән киленгә.

Таралыр күрше-күләнгә
Сандыктан бүләкләре...
Урын алырлар шушында
Сабые күлмәкләре.

...Челтәрле сандык туй белән
Кияү өенә төшәр.
Кыз чагының төсе булып,
Түрендә гомер кичәр.

## ТАУДА

Эштән бушаган арада,
Тауларда чыр-чу килеп,
Без дә чана шуа идек,
Казлар кебек тезелеп.

Кайгырмадылар әнкәйләр,
Кайтырлар дип үзләре...
Ишәлтауда бардыр әле
Безнең чана эзләре.

Без дә чана шуа идек,
Сикәлтәләрдән очып.
Кайчагында әнкәйләргә
Сиздерми, качып-посып.

Үзгәрә безнең карашлар,
Үзгәрә заманалар.
Әти-әни саклап тора –
Чана шуа балалар.

Тау башына баскан килеш
Мин дә изим кулымны,
Уйнаганына сөенеп
Кызым белән улымның...

## ИРЕК МӘЙДАНЫ

Ирек мәйданына җиту кирәк
Саф-саф булып барган халыкларга.
«Коммунизм» һәм «Яшәсен» сүзе
Шул ташкында гөрләп агып бара.

Шул ташкында «Ура!» кычкырмаса,
Тешләкләрнең эше уңмый, имеш.
Кеше белән бергә торган кеше
Җәмгыятьтән азат булмый, имеш.

Ирек мәйданында вәсвәсәне
Азатлыктан өскә күтәрдекме?
«Җәмгыять – без» диеп инанганга
Бәйле килеш гомер үткәрдекме?

Меңәрләгән Ирек мәйданында
Мәйдан тоткан мескенлекне күрдек.
Бүген менә Ирек мәйданына
Чын Ирекне эзләп кабат килдек.

Әләмнәре белән күзне буган
Шул мәйданга чыгып киңәштек без.
«Үзебез» дип йөргән җәмгыятькә:
– Син – ялганчы! – диеп эндәштек без.

Тигезсезлек хөкемдарларының
Хөкеменнән үлеп терелдекме?
Ирек мәйданына – илен җуйган
Кырым татарыдай без килдекме?

«Халыкчанлык» дигән сүз астында
Сүз иреге кат-кат кысылганга –
Сүзсез көрәш ысулына күчеп,
Ачлык игълан иттек шул мәйданда...

Безнең ташкын бәйрәм түгел бүген,
Безнең ташкын сыймый ярларына.
Хаклык өчен күтәрелүдер бу –
Ирек даулап – Ирек мәйданында!

## СИҢА КАЙТТЫМ, АКТАНЫШ!

Сиңа кайттым, туган ягым,
Сиңа кайттым, Актаныш!
Әнә берәү дәшә миңа:
– Исәнме, таныш тавыш!

Шундый бер кыз бар иде, ди,
Шундый иде тавышы...
Әй карыйм, карыйм текәлеп:
Бәлки, минем танышым?

Елларга юллар тоташкан,
Яшьлеккә кайтып барыш.
Үткәннәргә юлны ябып,
Алга дәшә Актаныш.

Яшьлегемә кайтам, имеш...
Юк, бүгенгә яраклаш!
Төстән түгел, тавышымнан
Танып ала сабакташ.

Еллар үтә, без дә башка,
Тавышлар гына таныш.
Дөнья күпме үзгәртсә дә,
Таны мине, Актаныш!

## КҮШЕГҮ

*(Юл кыйссасы)*

Сәфәр чыксаң, таныш-белеш кирәк.
Юл кыскарак була сөйләшкәч.
Бер вагонга туры килде менә
Өлкән агай, сүзчән милләттәш.

Сәфәр чыккач кына түгелдер ул,
Иптәш кирәк һәрчак кешегә.
Юлны гына кыскартыргамыни,
Гомерләрне сузар өчен дә...

Һәрбер сүзен күңелемә салып,
Тыңлап барам аны алай да.
Күрәм инде, үзе сөйләгәнне
Тыңлаучы да кыйммәт агайга.

Бер елмаеп, бер моңаеп сөйли:
– Балаларым аңлы, белемле.
Кыенсынып куям кайчагында,
Наданлыкта тотып үземне.

Сагышларны, сугышларны кичтем,
Уку кая безнең буынга?
Үзем алалмаган шул белемне
Күрим, дидем, кызым-улымда.

Икесе дә – теләкләрем кабул –
Урысчалап сөйли теттереп.
Шулар белән аңлашырга теләп,
Сүзләр эзлим бик еш, интегеп.

Ялгыш әйтсәм, төзәтә дә кызым,
Колагыма кадәр кызарам.
Татарчасын алар өйрәнмәде,
Сөйләшеп тә булмый үзара...

...Сәфәрдәшем сөйләп бара шулай.
Тыңлаучысы булгач, сөйләсен.
Ә мин дәшмим, беләалмыйм никтер
Мондый чакта нәрсә диясен.

Ихлас сүзен уртаклашыр өчен
Иптәш тапкан олы кешегә
Әйтелер күк: «Менә шуңа күрә
Җылы эзләп җаның күшегә».

Юл кыскара... Әйтелмәгән сүзем
Күңелемне килә озатып:
«Үз балаңа күчә алсаң гына,
Үз балаңда җаның калса гына,
Гомерләрне була озайтып».

Гомерләрне була озайтып.

## КАДЕРСЕЗЛЕК

Дөнья буйлап җәяү китеп барам, –
Хәерлегә... әллә хәерсезгә?
Дөнья тулы кеше арасында
Әверелеп була кадерсезгә.

Дөньясы да кадерсез бит аның.
Җаннарыбыз мең йозакка бикле.
Сабыр төбендәге алтын белән
Юлга чыксак... җитәр кая тикле?

Кая җитсен? Андый гына алтын
Күптән үтте кадерсезлек чиген.
Бөкрәйтәбез билне, күтәргәндә
Дөньябызның шул кирәксез йөген.

Безнең шушы бөкре гәүдәбезне
Турайтырмы әллә кабер генә?
Урам буйлап уйлар уйлап барам, –
Хәерсезгә, әллә хәерлегә.

Урам буйлап җәяү барышларым.
Дөнья тулы япа-ялгыз кеше.
Ауды берсе – кадерсезлек йөген
Күтәралмый кинәт чалкан төште.

«Ярдәм кирәк, ярдәм!» – дия-дия,
Әрле-бирле халык йөгереште,
Һәрберсенең бер кадерсез булып
Яшәвеме исләренә төште?

Дөнья тулы япа-ялгыз кеше,
Җаннарыбыз мең йозакка бикле...
Авар өчен кемгә чират хәзер?
Баралырбыз тагын кая тикле?

Сабыр төбендәге алтыныбыз –
Рухи байлык дигән зур хәзинә –
Кая кадәр алып барыр безне
Һәм аударыр икән кайсы җирдә?

Заман калыбына сыялмаган
Кадерсезләренә бирче көчең,
Йа бер Ходам! Үз дөньябыз йөген
Кабергәчә армый илтер өчен.

## ИКЕ ФӘЛСӘФӘ

Яшь кешенең фәлсәфәсе гаҗәп:
Бәхет эзләр офыклардан ары.
Сүзсез генә яшен коеп торыр
Бакча артындагы тупыллары.

Агачларга күзе төшәме соң?
Алда шатлык – тупыллардан олы!
Офыкларга китеп күмелгәч тә,
Ишетелеп торыр дәртле җыры...

Карт кешенең фәлсәфәсе башка:
Туган якка юлы, туган якка.
Моңаешып калган тупыллары
Ничә еллар буе шунда тарта.

Туган яктан күңел бизәме соң?
Җырлары да моңлы – сагынганга.
Мөлдерәшеп күз яшьләре тама,
Тупылларга килеп кагылганда...

## ОЛЫ КОЕ

Олы кое дип йөртәләр аны,
Булган, димәк, бездә кечесе дә.
Берсе калган бары – Олы килеш,
Изге килеш – авыл кешесенә.

Таң кызының серле көзгеседәй
Тау астында ята онытылып.
Бизәнешеп торган тупыллардан
Көлеп узган була ап-ак болыт.

Ындыр артлап сукмак салынгандыр
Без яшәгән гасырлардан элек.
Төшкәннәрдер кызлар безнең кебек,
Көянтәгә чиләкләрен элеп.

Юкка гына күк йөзедәй зәңгәр,
Җырдай моңлы булып тумагандыр:
Коеларча тирәнлеге белән
Бик күпләрнең серен тыңлагандыр.

Шул коеның агач улагыннан
Шук егетләр атлар эчергәндер...
Үлеп бара торган Олы кое
Шул чакларын искә төшерәдер.

Урамнарда хәзер колонкалар...
Олы кое керсез балачакның,
Яшь гомернең ихлас матурлыгы,
Горурлыгы булып калачактыр.

Читкә киткән егетләре килеп
Юаналар монда, ялга кайтса.
Яңарганнар әнә сиртмәләре,
Юлларында – култыксалы басма.

Туган җирне җирсеп кайтканнарга
Олы кое мөлдерәмә тулы...
Күк йөзедәй якты күзгесендә
Балкып уйный назлы кояш нуры.

Көязләнеп әнә, сихерләнеп,
Тупыллары тора онытылып.
Сукмак буйлап кызлар төшеп килә,
Йөзеп килә күктән ап-ак болыт...

## ГАРМОНИЯ

Табигать, сөеп кешене,
Батырлык һәм көч биргән.
Яшәү тәмен эшкә салып,
Уңганлыгын үстергән.

Тормыш гүзәл булсын диеп,
Мәхәббәт хисен биргән.
Кешенең җирдә яшәве
Изгелек өчен дигән.

Каршылыклар, киртәләрне
Көрәшсен өчен өйгән.
Явызлыкны җиңсен диеп,
Нәфрәт белән үч биргән.

Үчне һәрчак алга куеп,
Ерткычланмасын ялгыш
Дип, кешегә чиксез итеп
Сабырлык биргән язмыш.

## ПАР ИМӘН

Авылыма кайтып киләм
Сагынып, ямансылап.
Юл читендә пар имәнем
Шаулый, мине каршылап.

Алар – минем балачагым,
Алар – минем яшьлегем,
Сикәлтәле юлда үткән
Мәшәкатьле һәр көнем.

Юлда булган киртәләрне
Әйтерсең алдан тоеп,
Алар мине озаталар,
Иңемә канат куеп.

Кайткан чакта, пар имәнем
Шаулый, мине каршылап.
Балачагым көтә кебек
Сагынып, ямансылап...

## ТӨШЛӘРЕМӘ КИТӘМ

Төшләремә китәм, төшләремә...
Чынбарлыктан арган көннәрем бу.
Яздан, күктән, синнән җылы көтеп,
Яктылыктан өмет өзгәнем бу.

Төшләремә китәм.
Төшләремдә
Кемне күрсәм, шуның – ачык җаны.
Мин үзем дә күз яшедәй чиста,
Анда сафлык, анда пакьлек бары.

Һичьюгында, төшләремдә димен,
Чынга ашсын теләк-хыялларым.
Өнемдә мин беркайчан да алай
Тоташ ямьгә ия булалмамын.

Мин хыялый, төшләремә китәм –
Күңелемне алдар төннәрем бу.
Яздан, күктән, синнән җылы көтеп,
Көнгә төнне кушып үргәнем бу...

## ПЕСИЛЕ ТАЛ ЗАРЫ

Су буенда тал үсә,
Башын киссәң, тагы үсә.

*Халык җырыннан*

Дулкын шавы иркәләсә безне,
Кирәк түгел урман, болын да.
Мин дә үстем Казансуга карап,
Бөдрәләрем чайкап суында.

Казансуны бозлар каплаганда,
Ташуларны көттем зарыгып.
Туңмасын дип йомшак карлар яуды,
Чыбыкларга калды ягылып.

Песи кебек иркә бөреләрем
Табигатьтән күчкән наз иде.
Ямьнәреңне язга, җиргә биреп,
Мәңге шулай матур кал иде!

Булмады шул! Кешеләре кырыс.
Сөймәделәр җирем, суым кебек.
«Песиле тал!» – диеп ымсындылар,
Бәгыремне таладылар килеп.

Башын киссәң, тагы үсә, имеш,
Кисмәделәр юкса башны гына...
Җәрәхәтле җаным агар инде
Казансуның ярсып ташуында.

## ОЯ

Көннең бүген күңеле тулган,
Яшь коя да яшь коя.
Качар идем бу сагыштан –
Тапсагызчы бер оя!

Ул ояда якты булсын,
Оныттырсын болытны.
Югыйсә бүген үзем дә
Тискәрерәк холыклы.

Ул ояда җылы булсын
Күшеккән күңелемә.
Яшьле көнем үзе миңа
Теләсен иярергә.

Иярсен, әйдә, иярсен,
Керсен күркәм ояга,
Җылысында эресен дә
Оялсын яшь коярга.

Эзлик әле шундый оя,
Яктырсын бөтен дөнья!

## ГОМЕР

Чыклы үләннәргә беренче кат
Тәпи басып йөгереп киткәндә,
Эссе көндә тирләп-пешеп уйнап,
Үзәк өзелеп тамак кипкәндә,
Чишмә суы – татлы ширбәт,
Яшәү үзе – татлы ширбәт,
Учларыңнан эчеп була,
Бәллүр савыт нигә кирәк?

Яшьлегеңдә яшерен генә сөеп,
Йөрәгеңне ялкын ялмаса,
Яраларың әрнеп сызлаганда,
Дәваларлык чараң калмаса.
Мәхәббәтең – әче шәраб,
Яшәү үзе – әче шәраб,
Йотып җибәр дару итеп,
Савытына торма карап.

Шәраб кайгысымы уйлы башта,
Гомер юлы шундый мәшәкатьле...
Әллә агу, әллә дару кирәк
Ачкан чакта ачы хакыйкатьне:
Гомер юлы – мәңге яну,
Яшәү – агу, яшәү – дару
(Савытлары – мөлдерәмә)!
Эчкән саен исән калу,
Эчкән саен исән калу!

## КАРШЫЛАУ

Авылыма кышын кайтсам әгәр,
Ишәлтаудан юллар бар микән?
Әллә инде күкләр белән тоташ
Уйнап торган буран, кар микән?

Авылыма язын кайтсам әгәр,
Ишәлтауда чирәм шытармы?
Мин кайтканны күреп, ян бакчадан
Сыерчыклар каршы очармы?

Авылыма җәен кайтсам әгәр,
Яшел булыр микән Ишәлтау?
Эндәшерме зират наратлары:
– Кайттыңмы, – дип, – бахыр, исән-сау?

... Авылыма кайтып киләм менә,
Ишәлтауга менәм ашкынып.
Күңелкәем ташып тулгангамы,
Каршы ала болыт яшь коеп.

## И ТУГАН ЯГЫМ...

... җил дә вакытында исеп,
яңгыр да вакытында ява.

*Г. Тукай*

И минем туган ягымның
Кышлары да җәйләре,
Өф-өф итеп өреп эчкән
Мәтрүшкәле чәйләре.

Илдәшләрнең, җирдәшләрнең
Былбылларга хас теле.
Кадерләре елларга тиң
Һәр көне дә һәр төне.

Үтмәс борын сагындыра
Һәр бәхетле мизгеле.
И Илаһым, үз җиремнән
Мәхрүм итмә Син мине!

Җәйне җәннәткә тиңлиләр,
Кышларымның үз яме –
Илкәемнең ак хыялга,
Әкияткә тиң мәле.

Әгәр җәннәт насыйп булса –
Хакның мәңгелек җәе,
Кышларымны сагынып, димен,
Мин яңадан үлмәмме?

## ШАУКЫМ

Әй-йа, халкым, сиңа һәрбер шаукым
Мәңгелектән килгән канун кебек.
«Югары»дан төшсә бер-бер фәрман –
Әҗәлләрдән саклар дару кебек.

Фәрман булды мәчет салырга да:
Гөнаһларны йолыр чамалар бар.
Бер-бер артлы мәчет, мәчет калка,
Авыл саен айлы манаралар.

Әй-йа, халкым, гөнаһларың – ташкын!
Ташкыныңда ташлар арта тора.
Бу кадәрен уйлар чамалар юк,
Ярлыканыр! – Мәчет сакта тора.

Дөнья җитеш, дөнья түп-түгәрәк!
Тыныч кына мөмкин үләргә дә...
Күзгә күренмәгән Иблис бии
Мәчетләрдән төшкән күләгәдә...

## ИСКЕ ӨЙ

Өй сүтәләр. Иске өй сүтәләр –
Урын кирәк яңа урамга.
Тик аңламый шуны алабай-эт,
Аякларга өреп урала.

Кешеләрнең сәер гамәленә
Эт акылы ничек җитсен ди?
Әнә инде күз алдында кими,
Юкка чыга чүгеп иске өй.

Өй сүтәләр.
Өй генә дә түгел...

Ямансулый әнә хуҗа да:
Үткән гомер, аккан сулар бит ул –
Уйлана да тагын кузгала.

Балалары үсеп, канат ярган
Җылыдан да җылы оя бу.
Дулкын каккан, давыл кискән чакта
Бирешмәгән ныклы кыя бу.

Карлыгачлар оя корган нигез,
Үрмә гөлләр үскән бакчасы.
Ишегалларында яшел чирәм –
Юкка чыга менә барчасы!

Өй сүтәләр, яңа фатирлары
Шәп тә шәбен, иркен, зиннәтле.
Тик сүтелә монда яшь гомерләр,
Хатирәләр сүтелә нихәтле.

Сурәте дә калмый яшь гомернең,
Өе белән бергә югала.
Алабае шуны сизә бугай –
Аягына килеп урала.

Яңа фатир һәйбәт булуына
Эт акылы ничек җитсен ди?
Урамга да киңрәк урын кирәк,
Кичер инде, кичер, иске өй...

## ТУГАН КӨН

*Энем Рамилгә*

Өй буенда үскән үрмә гөлләр
Керфекләрен инде йомгандыр.
Чәчәкләрне, таллар, тупылларны
Көзге җилләр сыйпап узгандыр.

Сиңа әле кырык та юк икән,
Көзләреңә, димәк, бик иртә.
Ә гөлләрне – көзме, кышмы анда –
Күңелләрдә саклыйк ничек тә.

Бирешмәсен язмыш җилләренә
Балачакның тере бакчасы.
Миңа да бит, яшәү сутын эзләп,
Кабат-кабат шунда кайтасы.

Сиңа әле кырык та юк икән –
И сөендем, искә төште дә.
Син – сакчысы гөлләр бакчасының,
Көзләрдә дә кырау төшермә!

## ДӨНЬЯ КАЛА...

– Кеше киткән саен, дөнья бетә,
Калганнарга кала әле дөнья... –
Дип әйтте дә китеп барды әнкәй,
Һәм җылысыз калды безнең оя.

Кемнәрнеңдер дөньялары бөтен –
Яктылыктан, нурдан гына тора.
Безнең күктә авыр соры болыт
Түбәбезгә бозлы яңгыр коя.

Үз дөньясын алып китте әнкәй,
Кителепләр төште безнеке дә.
Ахыргача бөтенәймәс хәзер,
Мөмкин булмас аны төзәтергә.

Ис китмәгән әнкәй исән чакта,
Безгә гүя дөнья мәңге кала.
Киткәннәргә дөнья бетәдер шул,
Китмәгәнгә дә бит... кими бара!

## ЮК...

Яшәвемнең инде мәгънәсе юк,
Хат язарга якын кешем юк,
Көннәремнең нурлы кояшы юк,
Төннәремдә татлы төшем юк.

Башкаемда бетмәс уйларым бар,
Җанга кабык – сыным-буем бар.
Минем хәлдән гафил бу дөньяда
Ыгы-зыгы, бетмәс уен бар.

Үз башыннан кичми аңлаучы юк,
Чит кешенең читтә эше юк.
Бу йөрәгем ничек туктап калмый,
Җирдә әнкәм – газиз кешем юк!

## КҮЧӘ КОМНАР...

Ишәлтауның инде яртысы юк,
Бульдозерлар һаман кимерә.
Шул тавымның ком бөртеге итеп,
Җилпеп атты язмыш мине дә.

Комнарда – ком, үләннәрдә – үлән...
Ул тыгызлык күптән югалган,
Үз тавыма кайтып ятар идем,
Үз оямда инде булалмам.

Ашый бара заман бульдозеры
Балачакның текә тауларын.
Насыйп булган минә кичерергә
Тауларның да иңрәп ауганын.

Чит якларда минем үз тавым юк,
Мин – адашкан бер ком бөртеге.
Әллә еллар, әллә җилләр шулай,
Әллә язмыш уйнап бөтерде...

Күпме таулар тагын ишелде?
Күпме комнар... минем шикелле?

## БУ ДӨНЬЯГА ШАГЫЙРЬ ТУДЫРЫП ТА...

*Тукай әнисе Бибимәмдүдәгә*

Пәйгамбәрен Ходай ялгыз итә,
Ата-ана назын белмәсен дип.
Шагыйрен дә. –
Бары бер Ходайдан
Рухи җылы, илһам эзләсен дип.

Язылгандыр «Ләүхелмәхфүз»ендә
Ятим калу безнең шагыйрьгә дә.
Баласына шуны мирас итү
Татар кызы Бибимәмдүдәгә.

Язылгандыр «Ләүхелмәхфүз»ендә
Изге ана Бибимәмдүдәгә –
Үз халкына шагыйрь мирас итеп,
Ахирәткә күчү, күләгәгә.

Баласының кайгы-шатлыгында
Гомер итүләрдән мәхрүм ана!
Бу дөньяга шагыйрь тудырып та,
Шуны белми калган мәрхүм ана!

Шигърияттнең бакый галәмендә
Улың исеме йолдыз булып яна.
Зур шагыйрьнең япь-яшь анасы син,
Гомерләрең үтмәгән лә зая.
Үлемең дә хәтта... түгел зая!

## МОКЫТЛЫК

– Аша да йокла, йокла да аша, –
Моннан да җиңел фәлсәфә юктыр.
Яшәүдән башка мәгънә эзләүче –
Билләһи, менә чып-чын мокыттыр. –

Нәрсә дип әйтим бу фәйләсүфкә,
Аңлата алмый башларым катты.
Аның иманы үзенчә дөрес,
Ә миндәй «мокыт» үзенчә хаклы.

Чакмага чакма! Ут чыгар иде,
Бәхәс дигәнең мәгънәле булса.
Рәхәт яшәүдән ваз кичкән булып,
Мин дә әллә ни кырмадым юкса.

## БУ ЗАМАН

Явызныкы бу заман,
Ертлачныкы бу заман.
Ахрысы, мин беркайчан да
Бу заманча булалмам.

Судан коры чыга белмәм
Тыштан ак калыр өчен.
Үз-үземне үзгәртергә
Җитмәстер, ахры, көчем.

Суксалар да еламам,
Елмаюдан узалмам.
Аптыраудан көләргә тик
Өйрәтә мине заман.

## СҮЗГӘ «МӘДХИЯ»

Берәү нотык сөйли,
Берәү тәкъдим кертә,
Берәү вәгазь укый,
Берәү киңәш итә.

Хаклысы да сөйли,
Хаксызы да – оста.
Яшәү – уен, анда
Сөйләүчеләр ота.

Кемнекедер дөрес,
Кемнекедер ялган...
Умартадай гөжләп
Кайнап тора дөньяң!

Мәхлук булып калма:
Сөйләүчегә – ура!
Сүз ташкыны бүген
Җир күчәрен бора.

Берүк читтә калма:
Умартадан – кая?!
Кәрәзләре буш тик,
Җәйләр генә зая...

## ҮЗГӘРЕШ

Бигрәк кыска бу гомерләр –
Яздан көзгәчә генә.
Яшел яфрак – яшь йөрәкләр
Язларында сөенә.

Яшим диеп сөенәләр,
Лепердиләр җилфердәп.
Җәй буена күпме хисләр
Кичерә яфрак-йөрәк.

Яшел кала кайсы берсе,
Кайсы янып кызара
Һәм саргая...
Моңаешып
Шыбырдыйлар үзара.

Бигрәк кыска бу гомерләр,
Җәйләр узганчы гына,
Янып көйгән яфрак-җаннар
Җилдә тузганчы гына.

Яфрак-йөрәкләр очалар,
Рәхмәт дип җәйләренә...
... Язда без дә яшел идек,
Аһ, ничек үзгәрелә!

## АҺ, БАЛАМ!..

Тирә-якта дус бар, дошманым бар,
Тормыш дәрьясында чайкалам.
Кемгә кирәк соң мин дип уйлыйм да
Көфер уйны куып тукталам:
– Аһ, балам!

Нинди матур минем дөньям, димен,
Ай-кояшка карап сокланам.
Шөбһәле төш күреп уянсам да,
Зиһенемнән читкә аткарам:
– Аһ, балам!

Күләгәләр кунса күзләремә,
Көзге көнгә сылтап акланам.
Төн карасы көнне каплаганда,
Бер уй белән бары ак калам:
– Аһ, балам!

Айкалганда тормыш дәрьясында,
Кем соң мине исән саклаган?
Күпләр белгән гади хакыйкатьне
Өр-яңадан ачып шатланам:
– Аһ, балам!

## РӘССАМ ИСТӘЛЕГЕ

Күзләре зәңгәр иде,
Кашлары кара иде,
Кояш нурына уралып,
Яр буйлап бара иде...

Авыр толымнарын үрә-сүтә,
Чалынды да рәссам күзләренә –
Шул мизгелнең сүнмәс нуры булып,
Әверелде әкият гүзәленә:

Күзләре зәңгәр килеш,
Кашлары кара килеш,
Кояш нурына уралып,
Яр буйлап барган килеш.

Гүзәлкәйгә сокланырга кала
Рәссамының хыял киңлегенә.
Үзеннән дә матур төште бугай
Аның җансыз ап-ак киндеренә:

Күзләре моңлы булып,
Кашлары кыйгач булып,
Күңел тулы җырлары
Эченә сыймас булып.

Шул мизгелне искә төшерә дә,
Күңелләре китә нечкәреп.
Аны уйлап, үз сурәтен саклый –
Рәссамыннан калган истәлек.

Күзләре зәңгәр аның,
Кашлары кара аның,
Иреннәре елмайса да,
Йөрәге яна аның...

## МӘКТӘПКӘ КАЙТУ

Саумы, мәктәп!
... Син безнеке түгел.
Безнең мәктәп безнең балачакта,
Киләчәккә инде кайта алмас,
Хәтер кебек басып калган сакта.

Безнең мәктәп ерак балачакның
Һәр минутын элеккечә саклап,
Хатирәләр булып яшәр өчен
Бүгенгегә кайтмас инде, кайтмас.

Яңа дивар монда, яңа идән,
Яңа буын укый, яңа шау-шу...
Иске мәктәп кебек картайган без
Һәм яңасы кебек яшь һәм ярсу.

Мәңге сүнмәс учак бит син, мәктәп,
Гел яңарып торган изге оя,
Әйтерсең лә еллар аермаган –
Буыннарның монда барсы сыя.

Колакларда гомер буе чыңлый
Кыңгырауның көмеш кайтавазы.
Саумы, мәктәп! Мөмкинме соң синдә
Күңелләрнең ташып чайпалмавы?

Еллар үтәр, чорлар белән бергә
Гел яңарыр диварлар һәм өйләр...
Тик барыбер яңа буыннар да,
Сиңа килеп: «Саумы, мәктәп!» – дияр.

## ҖЫРЧЫ ҖАНЫ

И мөкатдәс моңлы сазым минем,
Җырлы иттең дәртле җанымны.
Шул җырларым, сыймый күкрәгемә,
Чишмә булып тышка агылды.

Иксез-чиксез Идел киңлегенә
Алып чыкты чишмә юлларым.
Сусаганнар йотылып эчте аннан,
Мин җырладым һаман, җырладым.

И мөкатдәс моңлы сазым минем,
Горурлыгым, даным, шөһрәтем,
Синең кылда, минем җанда яши
Татар дигән ихлас милләтем.

Татар җырын илгә таратканда,
Чишмәләр дә туктап тыңласын.
Килер көннәребез якты булсын,
Җырларыбыз зарлы булмасын.

И мөкатдәс теләкләрем белән
Сәхнәләргә җырлап чыгамын.
Моңлы сазым чиртә сызландырып,
Сыкрандырып күңел кылларын...

## ЯЗУ – ЯНУ

Акылыннан яза-яза,
Бөтен халык яза...

*М. Әгъләм*

Язу белән тынсачы җан,
Төзәлсәче яра.

Үзгәртим бу дөньяны, дип
Әрнеп шагыйрь яза.
Бәгыреннән өзелеп тама
Кан шикелле кара.

Ут сулыйдыр, өзелеп тама
Каләменнән ялкын:
– Үтсен гомер, янсын җаным,
Аңлар әле халкым!

Әмма халык – гүя балык:
Дәшми-тынмый ага...
Чәбәләнә шагыйрь җаны –
Кан саркыган яра.

Юкка гына янмас шагыйрь:
Яңарыр, ди, дөнья...
Учакларны сүндерим дип,
Яңгыр гына ява.

Өметләрен сүндерми тик,
Киләчәккә бара.

Энә белән кое казый –
Яна-яна яза!

## ҖИДЕ ҖИЛ ЧАТЫНДА

Җиде юл чатында...
Җиде җил чатында
Җил искән тарафтан
Ут-уклар атыла.

Җәяләр киереп,
Җиде ук атканда,
Җиде ят бер уйда:
– Һәлакәт – башкага!

Җил исә төрлечә –
Мәшрикъتан, мәгъриптән...
Ут-уклар кемнәрне
Аударыр кинәттән?

Йөгерәм, өлгерәм
Җиде юл чатына!
Җиде ук сызгыра
Алдымда, артымда...

Минем җан кош булып
Күкләргә ашканда,
Җиде як исән-сау!
... Һәлакәт – башкага...

## УЙЛАМАГЫЗ

Эзләмәгез мине шигырьләрдән,
Шигырьләрдә генә түгел мин.
Күңелләрем тулып ташкан чакта
Җырга гына килеп түгелмим.

Мин шыбырдап явам яңгыр булып,
Нурлар булып җирне киптерәм.
Дусларыма сөйләп бушанам да
Дәфтәремә шуны төшерәм.

Эзләмәгез шигырь юлларыннан
Минем генә бары сурәтне.
Тәрәзәдән баккан боек ай да
Үз җырларын миңа өйрәтте.

Башкаларның хәсрәтен дә кичәм
Үземнеке итеп, көенеп.
Шуңа күрә минем язганнарны
Уйламагыз бары мин диеп.

## УЗМЫШ ЮК

Чыгып булмый торган кысалар бар,
Кичеп үтәлмәстәй сулар бар,
Чарасыздан җанда буран тузгый,
Ак карлары чәчкә куналар.

Аргы ярга һаман ымсындырып,
Су өстенә ятар бозлар бар.
Саксыз керсәң, таеп егылырсың,
Буыннарың әрнеп сызларлар.

Кар-бозларын гөрләвеккә салып,
Шаулап килер җылы язлар бар.
Аның саен: «Насыйп түгел!» – диеп,
Үчекләгән ерак ярлар бар.

Сине көткән иркә дулкыннар бар,
«Сау йөр!» дигән җикән камышлар.
Йөзәр идең – упкын-ташкыннар бар,
Узар идең урап – язмыш бар.

# *II. Төшләремә керәсең дә...*

## ПАРАДОКС

Күбәләктәй бу очыну,
Беләм, миңа килешмидер.
Акыллы һәм ыспай булып,
Җитди йөрү тиешледер.

Тиешледер. Әмма нишлим?
Читлекләргә сыймый җаным.
Хыялларым киңлегендә
Синең белән очам тагын.

Синең өчен, синең хакка
Күңелләрем күбәләктер.
Белмәсәң дә, сизмәсәң дә,
Бәхетләрем түгәрәктер.

Мәңгелектән кадерле лә
Шул бәхетле мизгелләрем.
Яныңа да китермичә,
Тирәңнән дә җибәрмәвең...

* * *

Диңгезнең дә яры бар,
Язларның да кары бар.
Шат йөзләргә сокланма син,
Аларның да зары бар.

Кошлар оча – күге бар,
Таянырга – җире бар.
Сабырлыгыма карама –
Түзүнең дә чиге бар.

## ЙОСЫФ-ЗӨЛӘЙХА

Төшләремә керәсең дә,
Зөләйхага Йосыф кебек,
Таң атканда юк буласың,
Үзәгемне өзеп-өзеп.

Юк, кабатлый алмам, ахры,
Зөләйханың дәртле җанын.
Күреп туймас сурәтеңне
Хыялымнан куам тагын.

Заман бүтән, уйлар башка,
Ерак калган кыйссалар да...
Сине күрсәм, тетрәп китәм –
Йосыф бугай син, чыннан да.

Юк, эндәшмәм, сине даулап,
Кыю булмам Зөләйхадай.
Учка кысам йөрәгемне:
Син чыннан да Йосыф бугай.

Безне кемнәр тиңли алыр?
Кичер мине. Вакыт – хаким.
Төшләремә керәсең дә:
– Саумы, Йосыф! – дип кабатлыйм.

## ЯҢГЫР ҖИЛЕ

Яңгыр җиле сине
Озатыша китте.
Миндә кояш калды –
Тәнем, җаным пеште...

Иреннәрем – ялкын.
Сүндерсәче яңгыр!
Озатыша киткән
Болытыңны калдыр!

Болытыңны калдыр.
Сау йөр үзең. Сау бул!
Сиздермәскә телим.
Теләкләрем – кабул...

Җаным пешә, тәнем.
Куырыла гәүдәм.
Әверелдем утка.
Ялкынымда – шәүләң...

Шифалы җил сине
Озатыша кайтты.
Юлларыңа, дөрләп,
Минем шәүләм ятты.

Теләкләрем кабул:
Сизмәдең син һич тә.
Атлап кына үттең.
Күңел күзең – читтә...

## КИҢӘШ СОРАП...

Киңәш сорап килгәнсең дә...
Лаектырмы мин аңа?
Көнләп торам: син булып бер
Яшәр идем дөньяда.

Син караган күзгә карап,
Карашым яшермичә,
Тик бер генә көн булса да
Яшәр идем югыйсә.

Йозакка бикләп җанымны,
Киңәш бирим ничекләр?
Бу язмышым, белмим, тагы
Мине ничек үчекләр?

Йомарладым хисләремне,
Бер төенгә төйнәдем:
Бәхетең булсын үзеңә –
Көннәрең һәм төннәрең.

Минем мескен, бичара җан
Янсын әйдә, дөрләсен!
Сөйләшик тә гөрләшик бер –
Киңәш сорап килгәнсең!

## ИХ, ӘГӘР ДӘ...

Минем сүзләрне сөйлисең,
Үзең беләсең микән?
Әллә инде юри шулай
Миннән көләсең микән?

Көлсәң ни дә көлмәсәң ни?
Миңа нигә анысы?
Рәхәт икән үз-үземне
Синең сүздән таныйсы.

Рәхәт икән – иреннәрең
Минем җырны көйләсә.
Их, әгәр дә күңел күзем
Нәкъ киресен күрмәсә!

Их, әгәр дә күңел күзем
Сукыр булса кайчакта,
Сизмәс өчен чит ялкынны
Син кабызган учакта.

Чит куллар сине иркәли,
Иренеңдә – минем сүз.
Юк, ялгышам. Аһ, ялгышам!
Миңа – чит ул, сиңа – үз...

## ҮРТӘШҮ

Юри генә мине үртисең син,
Башкаларга юри карыйсың.
Көнләшүен бер сиздерер әле,
Бер ачылыр диеп санйсың.

Минем дөньям синекеннән үзгә.
Синең дөнья – нигә янәшә?
Үз-үземне алдый-алдый һаман
Сөюемә каршы көрәшәм.

Юри генә сине үртәп йөрим,
Әйтерсең лә сиңа битараф.
Синең күзләр белән җанга үтеп,
Карап тора гүя бар тараф.

Бер-береннән көлгән булып шулай
Җаннарыбыз янып үртәшә.
Синең гомер көлеп үтеп бара
Минем гомер белән янәшә.

## СОРАМА

«Бәхетлеме син?» дип сорама да,
Күземә карап, иркәм...
Куркытырмын кебек бәхетемне,
«Әйе» дип җавап бирсәм.

«Бәхетсезме соң син әллә?» димә,
Җавабын бирмәм өзеп.
Азсынасың дип үпкәләп, миннән
Бәхетем качар кебек...

## ӘЙЛӘН-БӘЙЛӘН

Әйләнбәйлән уенына кердем,
Куллар кулда, дөнья түгәрәк.
Ялгыз түгел, ялгыз түгел һичкем,
Тавыш бөтен, җырлау – бергәләп.

Әйләнбәйлән уенына кердем,
Чыга алмыйм, уйнап туйсам да.
Чылбыр-чылбыр үрелешкән куллар
Була икән әле усал да.

Әйләнбәйлән уенына кердем.
Читтә тора, читтә – синең сын.
Атылыплар чыгар идем моннан,
Куллар кулдан ничек ычкынсын?

Әйләнбәйлән уенына кердем.
Минем хәлгә күзең сал инде!
Ничек дәшим? Үзең белеп мине
Бу чылбырдан өзеп ал инде!

## ӘЛЛӘ...

Әллә кайтам үз кыйблама,
Әллә китәм кыйбламнан?
Мин коенган көмеш сулар
Чайпалган да болганган.

Уйнап йөзгән балыкларын
Күрмим инде үтәли:
Әллә күлем алышынган,
Әллә үзем бүтән мин?

Уртасында кул җитмәслек
Төнбоеклар үскәнен,
Ай нурыннан туган гөлне
Хәтерлимен бит әле.

Чайпалса да, болганса да,
Мин йөзәсе сулар бу.
Ахрысы, түзә алмамын,
Чоңгылына чумармын.

Яшел чәчен иңгә салган
Чын Су анасы кебек
Яр буена чыгармын мин,
Бака ефәге киеп.

Тулган ай да хәйран калыр
Миндәге үзгәрешкә:
Бака ефәге киярмен,
Су әйләнер көмешкә.

Төнбоеклар үсеп чыгар
Күлләремдә яңадан...
Мин коенган сулар көмеш –
Китә алмам кыйбламнан!

## ЯҢГЫРДА

Әллә яшем, әллә яшен
Чагылдыра күзләремне.
Яшеренмим яшеннәрдән –
Тик син генә якла мине.

Юлларыма койган яңгыр
Елга булып аккан инде.
Чыдармын ла яңгырына –
Кар-бозыннан сакла мине.

Яланаяк сулар кичтем,
Кыен чаклар артта инде...
Сөйләгәннәр сөйләсеннәр –
Шулай да син акла мине.

Таянычым булалмасаң
Каккан-кискән чакта җиле,
Авыр булыр, тик түзәрмен –
Син кызганма, ташла мине!

## КАБАТЛАНУ

Мин үзем дә бик еш кына гаҗәпләнәм:
Әнкәй миңа ерактан да күренгән күк.
Минем тормыш аның кайгы-хәсрәтеннән,
Шатлыгыннан, бәхетеннән үрелгән күк.

Менә бүген бөтен дөнья моңсу миңа.
Беләм инде, әнкәй никтер моңланадыр.
Менә кояш яктырган күк булып китә,
Минем әнкәй елмаядыр, елмаядыр...

## СӘЕР, ДИМӘ...

Мин сине, дисең, аңламыйм:
Сүнәсең дә янасың.
Бернәрсәгә ис китмәгән
Тыныч чагың кая соң?

Әллә үзем аңлыйм, димсең?
Тик чыгарга омтылам
Сәер кыланышлар беләң
Шул сәер халәтемнән.

Сибелешкән хисләремне
Гүя төенгә төйним.
Уйларымда син генә дип,
Бер ышанырга телим.

Үз-үземне ышандырам...
Ә йөрәк теләмәсә?
Сәер, димә. Җаным синнән
Ярдәм көтә ләбаса!

Нишләсәм дә, син кабул ит
Гаепләми, көлмичә.
Син аңламый, кем аңласын,
Кем кичерсен югыйсә...

## НИЧЕК ЯРАТЫЙМ?

Алып кердең таң-сарайга:
– Монда кал, – дидең, –
Мәхәббәтем, йөрәгемә
Шифа сал, – дидең.

Утка очкан күбәләктәй,
Шундый сөендем.
Ул чагында хыялымда
Гел син, син идең.

Шул сарайда яшим хәзер,
Йөрәктә – яра.
Минем сөю төсе булып,
Ал шәфәкъ яна.

Мәгарәңдә минем яшьлек
Сүрелеп бара.
Синең исә хыялыңда –
Иркенлек, дала.

Күңел тулы сагыш кына,
Ничек таратыйм?
Яратмыйсың мине, дисең,
Ничек яратыйм?

## СИН ТҮГЕЛ

Эссе көндә сусап килдем,
Саф чишмәдер син дисәм,
Агуладың сиздермичә –
Чишмә түгелсең икән.

Ни өчен соң бөтен тәнем,
Җаным яралы дисәм,
Гөл-чәчәк дип үрелгәнем –
Шайтан таягы икән.

Күбәләк булып терелэм
Мин шайтан таягында.
Кайларга барып кунарга,
Кемнәргә таянырга?

Канатымда – җылы сулыш.
Син диеп тетрәп китсәм...
Назлый мине язгы кояш!
Юк, син түгелсең икән.

## ӘГӘР КИТСӘМ...

Күзләреңдә минем күзләр калыр,
Колагыңда минем сүзләр калыр.
Чәчләреңдә – минем куллар назы.
Ниләр әйтим тагын... моннан ары?

Синең җанда минем җаным яшәр.
Кемнәр сиңа минем кебек дәшәр?
Минем кебек бүтән бармы тагы?
Ниләр әйтим сиңа... моннан ары?

Янәшәңдә яңа парың булыр.
Мине уйлап көн дә күңлең тулыр –
Ташлап китсәм әгәр бу дөньяны.
Ниләр әйтим икән... моннан ары?

Ниләр әйтим икән моннан ары?
Моннан ары әллә сүзләр бармы?
Җан авазым йолдызларга аша:
– Авыр булыр сиңа миннән башка-а-а!

## ЖӘЛ

Керфек кагып карар идем –
Күзем жәл.
Тел тибрәтеп багар идем –
Сүзем жәл.

Кичә генә шашып сөйдем
Синеме?
Әрнеп жәллим һәрбер зая
Көнемне.

Күрер күзне сукыр иткән
Сөю жәл.
Искә алып «Гомер зая»
Дию жәл.

Синең хакта – бу соңгысы! –
Сүзем жәл.
Энҗе итеп нигә тезәм?
Үзем жәл...

## НӘРКИСЛӘР

Яз ямен күзләрдән яшергән
Кышымның тәрәзе бизәкле.
Күңелем күнгәндер, күрәсең,
Бизәкнең башкасы кирәкми.

Тик быел ашыкты нәркисләр –
Иртәрәк җанланды язлардан.
Арыну авыр шул алай да
Җаныңны каплаган бозлардан.

Наз иле яз ямен җибәргән –
Карашны нәркисләр иркәли.
Язларны зарыгып көтсәм дә,
Мәңгелек кышымнан китәлмим.

Өзелгән нәркисләр күп тормас –
Салкыннан тәрәзәм бозланган.
Әллә соң, чыннан да, җаныма
Җәйләргә чыгарга язмаган?

Уйларны чуалтты нәркисләр,
Зиһенне актарып ташлады:
Якты яз, нигә соң чәчәгең
Сагышым шикелле сап-сары?

## ТОЛ ХАТЫН

Ил авызын капласынмы
Яулык белән?
Үз күңелен ул бит илдән
Артык белгән.

Ил авызы ни сөйләмәс
Телдән телгә?
Ник дуслары, шик күрсәтеп,
Җанны телә?

Энә күзе аша кемдер
Дөя күрә.
Шул ваклыктан гаҗиз тора
Ара-тирә.

Хәнҗәр-күзен күңеленә
Төбәгәнче,
– Хәлең ничек? – дип әйтсәче
Тик берәрсе...

## КҮЛӘГӘ

Канатланмый күңел, канатланмый.
Синең янда минем күләгәм,
Күрәсеңме, очып китә алмый,
Тик тирәңдә йөри үрмәләп?

Күләгәләр белән җайлыдыр ул –
Юк теләге, шашкын хисләре...
Синең күңел оча канатланып,
Минем күңел әллә нишләде.

Күләгәле күләгәләр булмый,
Икебезнең берсе чын кала.
Син очасың, янәшәңдә минме?
Юк, күләгәм бары чайкала.

Яратуның зурдыр бәяләре –
Җаннарыңны ярып түлә дә...
Хакларының шулмы хаклануы:
Үлгән җан да мескен күләгә?..

## БИК САГЫНГАЧ

Күзләреңне күптән күргәнем юк.
Миңа таныш шул ук сагышыңмы,
Язмышыңа үпкә-каргышыңмы,
Елларыңның елап агышымы –
Вакыт нинди эзләр салып үткән?

Күзләреңне күргәнем юк күптән.

Күзләреңне бик күрәсем килә.
Бәлки әле, чиксез шатлыкларың,
Кояшыңның якты балкышлары,
Бөтенләйгә кайткан яз кошлары –
Чагыладыр синең күзләреңдә?

Күрер идем күзләреңне генә...

## ЯШЬ АРАЛАШ КӨЛҮ

Син бу җиргә яратырга түгел,
Яраттырыр өчен яралган.
Белеп торам, сиңа гашыйк булам
Өр-яңадан, тагын яңадан.

Җитми сиңа минем сөю генә:
Күпләр сөйсен, күккә ашырсын.
Күреп торып шундый уйнак җанны
Яратуы бигрәк авыр соң!

Таһир өчен җанын кызганмаган
Зөһрә сыман үлсәм әгәр дә –
Сөенечтән күтәрелер идең
Күкләрдән дә биек мөнбәргә.

Яраттыру өчен җаның фида –
Үз-үзеңне артык сөясең.
Зөһрә булып синең өчен үлсәм,
Сөенечтән... син дә үләрсең!

## КҮҢЕЛ-КӨЗГЕ

Бөтенесен чагылдыра
Көлү – күңел көзгесе.
Бу дөньяда көлүнең дә
Була шул күптөрлесе.

Күңел-көзге яшералмый
Авызың кыеклыгын,
Уйдан уелган чагыңны,
Җаныңның боеклыгын...

Эчләренең эч керләре
Шәрран ачылыр дими –
Күңел-күзгә юньсезләргә
Юньләп күләргә бирми.

... Көләсеңме фәлсәфәмнән?
Синең алда – ачык мин:
Көлгән чакта сабый булып
Калуыңа гашыйк мин.

**НИГӘДЕР...**

«Яз» дигән тылсымлы ул сүзне
Ничек тә аңлата алмадым.
«Хат яз» дип әйтергә тартындым,
«Яз җитте» диепме аңладың?

Әй көлде соң кояш ялтырап –
Нурыннан күзләрем чагылды.
Оялды диепме уйладың? –
Нигәдер иңемә кагылдың.

Кулыңны этәрер көчем юк,
Йөзләрем гөлт итеп кабынды.
Йөгереп китәргә омтылдым –
Аяклар нигәдер абынды.

...Хушлаштык. Синнән гел хат ява.
Нигәдер бер җавап язмадым.
«Яз җитте» диюем булгандыр,
Син нигә «Хат яз!» дип аңладың?

## ГӨРЛӘВЕК

Кояшның язгы нурлары
Кагылуга үрелеп,
Гөрләвек булып йөгерә
Таудагы кар иң элек.

Юлындагы бөтен карны
Уята да челтерәп,
Йөгерә генә – диңгезгә үк
Барып җитәргә теләп.

Тик төннәрен туңдыра да,
Боз челтәрли чит-читен.
Инешләр соңрак уяныр,
Беренче булу читен.

Иң беренче күзен ача
Таудан төшкән гөрләвек.
Кечкенәме? Йөрәгендә –
Ташкындагы егәрлек!

## КАЕН ҖЫЛЫСЫ

Яз килгән дә, бусагадан узмый,
Кыш әлегә усал, куркыта.
Ап-ак каен бөреләргә тулган,
Өшерменме диеп ут йота.

Ак каеннар юлы ап-ак карлы,
Өсләрендә куян эзләре.
Шул эзләрне ашыгып исни-исни,
Төлке узып китте элгәре.

Чаңгы юллары да төзек әле,
Эремәгән, җиргә батмаган.
Ял көннәре җиткәч, чаңгычылар
Шуар әле тагын ак кардан.

Тик каеннар якынайта язны,
Каеннарның кайнар тәннәре:
Кәүсәләрен урап алган карны
Уеп кына төшкән мәлләре.

Тирәләре уйдык-уйдык үзән,
Бөреләр дә инде җылыныр.
Каен – кайнар! Ә кемгәдер бу яз
Үзе килгән төсле тоелыр!

## ЯРАТТЫРАСЫМ КИЛӘ*

*(Җыр)*

Тамчы булып, чәчләреңә
Уйнап тамасым килә.
Күңелеңдә ләйсән булып
Урын аласым килә.

Коштай очып, кочагыңа
Бер атыласым килә.
Иркәләнеп, бер мизгелгә
Онытыласым килә.

Күзләреңнән күзем алмый,
Карап торасым килә.
Үзем яраткан кадәрле
Яраттырасым килә.

---

* Луиза Батыр-Болгари көе.

## ОЧРЫЙ ГЫНА КҮРМӘ

Мин күралмыйм сине
Бик күптәннән инде.
Юлларымда минем
Очрый гына күрмә.
Мин күралмыйм сине.

Кыенлыклар изде
Безнең икебезне.
Без табышкан көзне
Уйда саклый күрмә.
Без табышкан көзне...

Мин оныттым күптән.
Сөю инде үткән.
Беткән әрнү, үпкәм.
Син хәтерли күрмә.
Сөю инде үткән.

Ерак булсын юллар.
Эзне җуйсын еллар.
Кочаклармын елап –
Очрый гына күрмә.
Очрый гына күрмә!

## РӘХМӘТ СИҢА

Рәхмәт, дустым,
Ташлап китүеңә,
Бу адымга
Килеп җитүеңә.

Рәхмәт, дустым,
Әгәр син китмәсәң,
Ышанычка
Хыянәт итмәсәң,

Гел нарасый
Булып йөрер идем,
Хыянәтне
Каян белер идем?

Кыен чакта
Ташлап китеп мине,
Көчле иттең.
Дустым, рәхмәт инде.

## ШАЙТАН ТАЯГЫ

...Чәнечкеле сабакларга
Мал да тимәгән.
Өзәргә дип янып сөйгән
Яр да килмәгән.

Чәнечкесен тырпайткан да
Чәчкән хуш исен.
Матур чәчәк аткан икән
Тик үзе өчен.

Мондый кыргый матурлыкны
Яратмый беркем.
Яр көтә шайтан таягы –
Өзми өметен.

Килә калса, гадәте шул –
Яралар тагын.
Кем шәфкатьле итә алсын
Шайтан таягын?

## ӘНКӘЙ

Ян бакчадагы шомыртлар
Инде яфрак яргандыр.
Олы юлга карый-карый,
Әнкәй, күзең талгандыр.

Шомыртлар чәчәк аталар,
Кайталмадың тагын дип,
Хат язарсың. Бер кайтырмын,
Көт син, әнкәй, сабыр ит.

Синнән алган йөрәк җылым
Сабыйларыма күчә.
Авылыма кайталмыйча,
Көн артыннан көн үтә.

Мәшәкатьләр бетми һаман,
Балалар да бәләкәй...
Серләремне сиңа сөйлим,
Төшемдә күреп, әнкәй.

## АК ЧӘЧӘК

Чукларын берәмләп саныймын,
Кулымда тирбәлә ак чәчәк.
Сөйгәнем сөяме, сөймиме,
Төп-төгәл ул әйтеп бирәчәк.

Әллә соң алдыймы чуклары:
Ярата, яратмый, ярата!
Ак чәчәк, әйт, нигә аңардан
Хатлар да килмиләр, ичмаса?

Елмая: сабыр ит, язачак.
Көтә бел, хәбәре киләчәк.
Чуклары коелды яшь кебек...
Сарыга сабышты бу чәчәк.

Шәп-шәрә сабакта моңаеп
Калган тик үзәге – сап-сары.
Берәүне юатып, елмайтып,
Үзенең саргайган чаклары.

## КЫЗ БАЛА

Кыз балага унҗиде яшь,
Күбәләк кебек.
Кайчан горур, кайчагында
Җилбәзәк кебек.

Кыз балага унсигез яшь,
Гөл-чәчәкмени?
Очкын кебек күз карашы
Сүнәчәкмени?

Бәхет өчен тугандыр ла –
Шуңа очына.
Әнә инде акны кигән –
Кияүгә чыга.

Әнә инде нарасыен
Назлап иркәли.
Сөю, сагыш, бәхет һәм моң...
Белми киртәне.

Карашына олы дөнья
Гел күчә бара.
Шушы бәхет өчен, ахры,
Туа кыз бала.

## МИН – КҮБӘЛӘК

Мин – бер көнлек күбәләкмен бары.
Иртәгә дип вәгъдә бирмә син.
Канатларым, җилпенгәне саен,
Коя әнә бизәк-сөрмәсен.

Иртәгә дип син юатма мине,
Ул «иртәгә» юктыр, кем белә.
Мин – бер көнлек күбәләкмен бары,
Шуңа күрә бүген кадерлә.

Кайнар сулыш, якты караш белән
Җылыт мине шушы мизгелдә!
Аһ! Иртәгә? Алайса юк,
Кирәкмисең миңа үзең дә...

Мин – бер көнлек күбәләкмен бары!

* * *

Без – икебез.
Төн – әкият.
Кар да – йолдыз.
Ай җылы...

Аерылыштык.
Көн караңгы.
Мин баскандa,
Кар җылый...

## ЯЗАР ИДЕМ...

Кич утырып хатлар язар идем,
Уйларыңда әгәр мин булсам.
Ай нурыннан балкыр иде дөньям,
Хыялымда сиңа сыенсам.

Ятмас идем хәтта йокларга да
Ул бәхетле нурлы төннәрдә.
Язар идем айлы каләм белән,
Хатларымны көтсәң әгәр дә.

Тылсым өреп ап-ак кәгаземә,
Яшь гомерне кире кайтарып,
Язар идем, язар идем сиңа,
Хисләремә үзем таң калып.

Ләкин беләм: гомер үтә тора,
Хыяллардан үзгә чынбарлык.
Айлы төндә шигырь генә язам,
Хат язарга сиңа оялып...

## «КАРА УРМАН»

Ярата дип йөрмә кәперәеп,
Син тугансың минем хыялда.
Кара урман кебек билгесез син,
Ниләр булмас кара урманда?

Ача калсам кара урман серен,
Яратмам да, бәлки, иртәгә.
Мин бүгенгә хыялыма гашыйк,
Горурлыгың белән үртәмә.

Болыт арасыннан бер күренеп,
Бер күмелеп калган ай сыман,
Йөзеп кара әйдә чиксезлектә,
Иртәгә мин сине юксынмам.

Иртәгә мин сине онытырмын,
Хыялымнан кинәт бушанып.
Мин үзем дә кара урман әле,
Кичерер дип йөрмә ышанып.

## СУ ӨЧЕН ГЕНӘ

Бәйләмә инде кара атыңны
Көн саен безнең капка төбенә.
Белеп торамын, туктыйсың юкса
Кое янына су өчен генә.

Бәйләмә инде кара атыңны,
Күрәм дә сине, өзеләм генә...
Суга чыгамын атлар-атламас,
Битараф булып күренәм генә.

Атыңны синең күрмичә узам,
Шаян сүзеңне ишетми генә.
Әмма көтәмен синең килүне
Көн саен шулай кичекми генә.

Бәйләмә инде кара атыңны
Капка төбенә су өчен генә!
Үзем дә беләм: көям дә кибәм
Юк өчен генә, юк өчен генә...

## ГӨЛ ГОМЕРЕ

Гөлләр шиңде, гөлләр шиңде салкын җилдә,
Япмаганмын тәрәзәмне төнгә каршы.
Мин шулкадәр аек уйлы кеше идем,
Белмим инде, зиһенемне ни таратты?

Гөлләр шиңде, гөлләр шиңде таң атканчы,
Кызганудан яшьләр тулды күзләремә.
Тамырлары исәндер бит, ышаныймы
Гөлләремнең өр-яңадан үсәренә?

Гөл гомере – гел яңару, терелүдер...
Тик бу көнем – шиңгән мәле гөлләремнең.
Сөйләп тормам сәбәпләрен. «Сине көттем
Зиһеннәрем таралганчы», – диярмендер.

Үзебез дә гөлләр кебек нәзберек шул.
Нечкә күңел тиз күшегә зәһәр җилдән.
Никадәрле батыр булып күренсәм дә,
Җилләренә ис китмичә яши белмәм.

Әче җилдән җан өшегән чак булганга,
Гөлләр шиңде, гөлләр шиңде таңга кадәр.
Мин үзем дә, гөлләрем дә терелер күк,
Сагынып килеп: «Хәлең ничек?» – дисәң әгәр.

## ЭНДӘШМӘВЕҢ БЕЛӘН...

Эндәшмәвең белән җәзаларсың,
Күзләремә сынап карарсың.
Кузгалырсың: «Китәм инде», – диеп,
Мин әйтермен бары: «Ярар соң...»

Эндәшмәвең белән җәзаларсың,
Авыр сулар бушлык арада.
Шул бушлыкны юк-бар сүзләр белән
Тутырырмын үзем кай ара.

Сүз кирәк, сүз! – бер йотым су кебек,
Эссе чүлдә калып сусагач.
Эчтән генә, бәлки, көләрсең дә,
Битләремне ялкын, ут алгач?

Килгән саен шулай китәрсеңдер,
Эндәшмәвең белән җәзалап.
Төштә генә көлеп сөйләшерсең,
Аптыраудан мине аралап.

Иртәгесен тагын килерсең дә
Сүзсез генә күзгә карарсың,
Кузгалырсың: «Китәм инде», – диеп,
Мин әйтермен тагын: «Ярар соң...»

## ХЫЯЛЫЙ ДИАЛОГ

– Матур сүзләреңне
Калдыр шигыреңә.
Купшы сүзләр никтер
Авыр күңелемә.

Назлап дәшәрсең дә
Күтәрсең, дим, җавап,
Куштанланыр өчен
Юк шул миндә талант.

Болай да бит синнән
Китәр сәбәп эзләп,
Сүз әйтергә кыймый
Йөрүем бу йөдәп.

Матур сүзләреңне
Шигыреңә сакла.
Күңел түрем салкын,
Тәрәзәсен какма!

– Синең күзләр миңа
Ялвардымы шулай?
Юк ла, бу – син булып
Үзем сөйлим бугай.

Ә шулай да хакмы
Мин уйлаган фараз?
Язып күрсәт син дә
Алып каләм, кәгазь...

## БАРЫ ТҮЗ

Мин башкача түзә алмыйм,
Мин башкача көтә алмыйм –
Бер сүз генә әйтче, зинһар,
Боз эрерлек назлы сүз!

Кышлар арты кышлар килә,
Кем өчендер – кошлар килә,
Ә мин чирдән айный алмыйм...
Сөю чире – бары түз!

Ул чиремнән оялам мин,
Яратудан кыйналам мин...
Язны көтмим, һичьюгында
Ярар иде сары көз!

Кышлар арты кышым көтә,
Үз-үземә һушым китә:
Бер сүз эстәп тилмерәмен –
Боз эрерлек назлы сүз!

## РӘСЕМ

Уфтанасың, барып таянасың
Кәнәфинең йомшак аркасына.
Дулкынланып, кулың кайнарлыгы
Күчә сыман ефәк япмасына.

Куырылып шуа ефәк япма
Көтелмәгән утлы тетрәнүдән,
Һәм кочаклый сине иңнәреңнән,
Агып төшә муен, күкрәгеңнән.

Күл-күзләрең чайпалгандай була –
Моң тамчысы әзер түгелергә...
Халәтеңне куркытудан куркам,
Рәсемеңне биклим күңелемә.

## ОЧЫШ

Күкнең җиденче катына
Канатланып очкан чакта,
Күбәләк җан утка керде –
Куырылып мең гөнаһта.

Күкнең җиденче катына
Җитүләрнең бәһасе зур:
Көйгән канат көлгә калыр,
Әмма очу – нинди хозур!

Күкнең җиденче катлары
Ымсындырып ник чакыра
Ак томандай тотрыксыз
Сөю дигән ак чатырга?

Кабат очып булмастыр шул –
Утлар төшсә канатыңа...
Ничек тагын күтәрелим
Күкнең җиденче катына?

## ИКӘҮ

Мин – куз гына, күмер генә!
Дөрләп китәм, тик өр генә!
Ә син – салмак, тымызык су,
Мөмкинме соң безне кушу?

Мин талпынам, хыялланам,
Учак булып эчтән янам.
Синең күңел күлдәй тыныч.
Күлдәй тыныч һәм... куркыныч!

Тыныч күлнең суы тирән.
Уйга калган нинди сердән?
Керер идем – ут чакларым,
Сүндерерсең учакларым.

Мөмкинме соң безне кушу?
Мин – утлы куз, син – суык су...
Тик барыбер кушылырбыз,
Икәү бергә юк булырбыз.

## КИТ!

Ишегеңне ачык калдырып кит,
Үтәли җил әйдә йөгерсен!
Тәннәремне алган кайнар утны
Һичьюгында өреп сүндерсен!

Ишегеңне ачык калдырып кит,
Бер сүзеңне көтеп көйгәндә,
Үтәли җил киссен бәгырьләрне,
Кайнар яшем кипсен җилләрдә.

Ишегеңне ачык калдырып кит,
«Китмә!» – дими чак-чак тыелам.
Таш кыядай калам, син китүгә
Убылам да төшәм, коелам.

Беләсеңдер кыя-ташларны да
Исә-исә җилләр кисәсен.
Ишегеңне ачык калдырып кит!
... Аңламагач, ни хәл итәсең?

## КАРШЫЛЫК

Син яшеннәр эзләп китеп бардың,
Карашыңда – яшен сурәте.
Хыялыңны читкә алып киткәч,
Болытларны килми күрәсем.

Яшеннәрдәнниләр көтәсеңдер,
Сызыла да үтә – бер мизгел!
Сабыр савытларым яңгыр юа,
Тамчылары инде йөз, меңдер.

Син яшеннәр эзләп йөргән чакта,
Болытлы көн – минем халәтем.
Мин бер мизгел түгел яшен кебек,
Мин яратмыйм яшен сурәтен.

Җылы биргән җир учагын сөям,
Син – яшенне. Ничек әрнетә!
Икебез дә утка гашыйк юкса,
Ике якта язмыш йөретә.

## ТӨЕН

Ялгызлыкка түзәм, түзәм,
Кадерсез яр булу кыен.
Нинди мәгънә мин янудан,
Синең өчен булгач уен?

Качыш-качыш уйный алмыйм,
Мин болардан туйган инде.
Уеннардан уймак чыгып,
Чәчкә аклар кунган инде.

Сабырлыгым ник сынайсың,
Яннарымда уйнап йөреп?
Өзеләм дә ялганамын
Төенләнгән җепләр кебек.

Күңелдә гел төен генә...
Синең күзләр көлә әле.
Кадерсез яр була күрмим,
Ялгызлыкка түзәм әле.

## ДӘВА

«Минем хакта ни уйлыйлар икән,
Минем хакта нәрсә сөйлиләр?
Килешәме атлап йөрешләрем,
Заманчамы минем киемнәр?»

Төзәтергә бармы чаралары,
Шундый булса күңел фаҗигаң?
Үз-үзеңне артык сөю чире
Язмышыңа, бәлки, язылган?

Сөю җибәр, Ходам, бичараңа –
Һәм бирәүгә аны гашыйк ит!
Һәм күзләрен үз эченә түгел,
Бу дөньяга төбәп ачык ит!

Ул яратсын шашып бер кешене,
Үз-үзен дә хәтта онытсын!
«Тел сөяксез, сөйләсеннәр, – дисең, –
Хет шайтаны килеп орышсын!»

Көзгеләрдән күзен алмаганы
Калсын бары көлеп сөйләргә...
Сөю җибәр, Ходам, үзен генә
Артык күргән шундый чибәргә.

Сөю җибәр, төзәт фаҗигасен,
Яктырыплар китсен дөньясы.
Авыр чирдән җанын араларга
Тик шул гына булыр дәвасы.
Сөю җибәр!..

## ЯРЫЙ ӘЛЕ

Син шулкадәр ерак, шундый ерак,
Сиңа юллар – гомер озынлыгы.
Яшьлек таңы очраштырган иде,
Алда хәзер – шәфәкъ кызыллыгы.

Баксаң, гомер шундый кыска икән –
Таңнан башлап, шәфәкъкача бары.
Мин, күрәсең, талчыкканмын синсез,
Ә сиңа юл – хыялымнан ары.

Үз-үземне хәтта сискәндереп,
Йөрәгемдә хисләр кайный әле.
Үткәннәргә кайту мөмкинмени? –
Син шулкадәр ерак, ярый әле...

## БИЛЛӘҺИ!

Уйларымны, барлыгымны биләп алдың,
Йокы качты төннәремнән, билләһи!
Күзең тутырып тик бер генә карадың бит,
Яшен үтте тәннәремнән, билләһи!

Минем хәлгә үзең кереп кара инде –
Төнем – ялсыз, тәнем – җансыз, чарам юк.
Ап-ак кәгазь серләремне тыңлар иде,
Язам дисәм, каләмемдә карам юк.

Зиһеннәре чуалмаган кешеләргә
Минем халәт – бер юләрлек, чын менә,
Ак һәм кара бу дөнья, дип кабатласам,
Синең сурәт аллы-гөлле күренә.

Күзең тутырып тик бер генә кара тагын,
Яшеннәрдән, ялкыннардан арала...
Юк, ышанма, юри әйтәм!
Рәхәт миңа
Менә шулай яшерен генә янарга...

## ХУШЛАШУ

Яшьлегемне бүләк итәм сиңа –
Иң шәп чагын, минсез үткәнен тик.
Минле көннәр күз алдыңа килеп,
Бүленмәсен татлы төшләрең дип.

Яшьлегеңнең минсез чагында кал,
Минле чакны каргамассың анда.
Барыр юлым авыр, хушлашыйм да
Чыгып китим каршы бураннарга.

Яшьлегеңнең минсез чагында кал,
Өстерәмә минле көннәр йөген –
Иңнәреңнән как та тузаннарын,
Кабат-кабат яшьлегеңә сөен!
Яшьлегеңне бүләк итәм сиңа...

## ҺӘЛАКӘТ

«Син әйткәнсең, дип әйттеләр...
Сөйләгәннәр... сөйләде...» –
Сүз дулкының көймәбезне
Кыяларга терәде.

Кыяларга менеп булмый,
Юллар ябык диңгезгә.
Чоңгылларда, бата-калка,
Йомычка-көймә йөзә.

Чоңгыл йотар мизгел җиткән,
Һаман кага дулкының.
Каршы җилгә күкрәк куям,
Юк җавабым, юк тыным.

Әйтер сүзем алтын булса,
Эндәшмәвем – көмештер.
Икебезнең беребез хет
Ир булырга тиештер.

## ЯФРАК

Ябык болдыр. Тик каяндыр
Сары яфрак кергән очып.
Тын почмакта урын тапкан
Яңгырлардан, җилдән посып.

Яфраккаем, хәлең мөшкел,
Язмышлардан булмый узып...
Кышкы буран чират көтә,
Көзне куа тузгып-тузгып.

Сары яфрак, сары яфрак,
Үткән инде гомеркәең.
Яшел җәең уйладым да,
Тулып китте күңелкәем.

Кер китабым арасына,
Сакланырсың, бәлки, озак.
Сиңа карап яз көтәрмен.
Ул көннәргә ерак, ерак...

## ЯЛВАРУ

Бул! Яисә... булма!
Булыр-булмас булып ләкин
Җанны үртәп торма!

Сүн! Яисә... кабын!
Сүнәр-сүнмәс күмер кебек
Пыскып торма тагын.

Кис! Яисә... ялга!
Тулы ирек бирелгәндә,
Гафил булып калма.

Юк?
Алайса булма!
Булыр-булмас яшәр өчен
Мин үзем дә бар ла!

## ӨЗЕЛГӘН ӨМЕТ

Бер сабак чәчәк бүләк ит,
Бер генә сабак...
Бәйрәм белән котла мине
Бер генә кабат!

Шул чәчәгең, бер карашың
Гомергә җитәр.
Язларымнан наз сорамам
Шул гөлдән битәр.

Чәчәгеңнең истәлеге
Җылытыр мәңге.
Бер генә чәчәк бүләк ит
Бәйрәмдә, яме?

Күңелемнән и ялвардым,
Юк, ишетмәдең.
Чәчәк түгел, күз нурың да
Бүләк итмәдең.

Бәйрәмемнең салкыныннан
Күшегәм хәзер.
Чәчәксез итеп исемә
Төшерәм хәзер.

## ОЧРАШУ

Үткән дә юк безнең, киләчәк тә,
Шушы мизгел бары берләштерә.
Синең – минсез, минем синсез үткән
Гомерләрдән калыр бер хатирә.

Яшьлек елларының хәбәре бу:
Син – бер ярда, мин бер ярда калган.
Бүгенгедә шәүлә генә безнең –
Хисләр тыйнак, сүзләребез саран.

Яшьлек тә юк безнең, мәхәббәт тә
Вәгъдә иткәч кабат кагылмаска.
Яратудан өстен яралган без,
Уйлар саллы, мәшәкатьләр башка.

Тик нигә соң әрни, сыкрый йөрәк,
Ник бу мизгел шушы кадәр кыска?
Гомер нигә искән җилдән җитез?
Күрешүләр безнең юкка, юкка!

Ә шулай да тыйнак, сабыр сүзләр
Бу мизгелдә безне берләштерә!
Синең – минсез, минем синсез үтәр
Киләчәккә калыр бер хатирә.

# *III. Алма бакчасы*

## АЛМА КОЕЛА

Алмалар пешкән, алмалар пешкән –
Алмагачларның бәхетле чагы.
Әмма бу мизгел – чәчәкле җәйнең
Дөрләп кабынган соңгы учагы.

Алма коела, алма коела –
Алмалар күмде инде бакчаны.
Көз якынлаша, әлегә җәйнең
Сагыш аралаш көләч, шат чагы.

Алмалар кызыл, бакча хуш исле.
Тик анда-санда яфраклар сары.
Ел да җәй килер, шушы алмалар
Кабатланырмы, туармы тагы?

## КАЙЧАНДЫР УЛ...

Яз көнендә тоташ чәчәк иде,
Яфракларын хәтта тоймады.
Ак болытка охшатты ул үзен,
Сөенече эчкә сыймады.

Алмалардан сыгылырга иде...
Алмагачның уе – көзләргә.
Тик көзгәчә, ай-һай, ерак әле,
Тик көзгәчә ничек түзәргә?

Алмалары яшел төймә иде,
Кемнәр күрде, кемнәр күрмәде.
Ул һәрберсен алтын алма итеп
Үстерергә генә теләде.

Күзләренә, ай-һай, ерак иде,
Алмалары тартты түбәнгә:
Сынып төште яшел төймәләре,
Инде үсә, үсә дигәндә...
... Кайчандыр ул тоташ чәчәк иде.

## ИКЕ АЛМА

– Алмагачта ике алма – без биектә.
Безгә һичкем карамаган бер тиеп тә.
Янәшәмдә – кызыл алма минем кебек,
Аның өчен алсуланып торам көлеп.

Аңа карап таң нурында коенам да,
Иртәнге чык суларында юынам да,
Җәйләремә озын гомер тели-тели,
Алланамын-балланамын кайгы белми.

– Җәй уздырдык күренмичә яман күзгә,
Ялгыз калу рәхәтмени моңсу көздә?
Әлегә без ике алма, ике алма,
Килгән кеше, берсен генә өзеп алма!

Алмагачта ике алма – без бик биек.
Биектәге ботакны да җиргә иеп,
Икебезне, икебезне өзеп була!
Бергә чакта өзелүгә түзеп була...

... Алмагачта яфрак та юк – көзләр үткән.
Кышкы җилләр кар сибереп йөри күптән.
Алмага да тия икән явыз язмыш:
Ялгыз алма карда өшеп калган ялгыш.

## ЯРТЫ АЛМАМ!

– Ярты алмам, ярты алмам кайда?
(Мине бөтен алма итәргә!)
Күпме җаннар парын эзли шулай,
Күпме җаннар әзер күтәргә.

Ярты алмам, ярты алмам кайда?
Үземнекен ничек табарга?
Сайлап алган ярым хата булса,
Ялгышырлар башка ярлар да.

Күпме алма буталышып калыр,
Күпме җаннар яшәр яртышар.
Мин ясаган бер хатадан башлап,
Кабатланып барса ялгышлар.

Тик бер хата... Меңәрләгән алма.
Меңәрләгән – бар да яртышар!
Шундый мәхшәр туачагын белсәм,
Мин ялгышмас идем, ялгышмам!

Ярты алмам!Ниләр язган сиңа?
Кем язмышын бөтен итәргә?
Синең янда кем ул бөтен яши,
Ярты килеш гомер үткәрә?

## АЛМАГАЧ

Өрәңге белән тамырдаш
Юл читендә алмагач.
Нишләсен соң үз язмышын
Үзе сайлап алмагач?

Алма бирү насыйп булган
Өрәңге кочагында.
Башкаларга охшамау да
Ярый ул кайчагында.

Ачсыннар күңел күзләрен –
Туктап үтсен кешеләр:
Өрәңге кәүсәсендә дә
Алма үсә, дисеннәр!

Меңнән берәү күрсен әйдә,
Алмагачка шул җитә...
Карашларын җиргә төбәп,
Юлчылар үтә-сүтә...

Инде үзен күрсәтергә
Өметләре калмагач,
Битарафларның башына
Алма коя алмагач!

## ӘЙ, АЛМА БИТ!

Әй, алма бит, алма бит, дип,
Алма битләр кала бит, дип,
Җырлап узаргамыни соң,
Җаннар сызаргамыни?

Әй алмасы, алмасы ла,
Башкаларга калмасын ла,
Үрелепләр алыйммы соң,
Куеныма салыйммы?

Әй, алмамдыр, алмамдыр шул,
Һич төзәлмәс ярамдыр шул,
Башларыма уй салды да,
Алам дигәч, югалды.

Әй алмалар, алмалар күп,
Учак булып яналар күк:
Берсеннән-берсе алсу да,
Тик күңелгә ямансу.

Әй, алма бит, алма бит, дип,
Алма битләр кала бит, дип,
Җырлый-җырлый моңаям да
Елап кына юанам.

# *IV. Яшьлек дәфтәреннән*

## ӨСТЕНЛЕКТӘ

*(Шаяру)*

Борын-борын заманнардан
Килгән күркәм гадәтләр
Бүгенге көн кешесен дә
Өйрәтәдер әдәпкә.

Үткәннәрдән күчкән шулай
Хатын-кызга хөрмәт тә:
Ишек ачкач, безне алдан
Уздыралар, әлбәттә.

Тик борынгы заманнарда
Булмаган ишекләре.
Хәвеф-хәтәр саклап торган
Мәгарә тишекләрен.

Хәйләкәр булган бабайлар:
Һәр караңгы тишектән
Әбиләрне уздырганнар,
Алдап-йолдап ничек тә.

Ә без бүген – күтәрелеп
Илаһи биеклеккә –
Сөенәбез үзебезнең
Бердәнбер «өстенлек»кә!

## УНҖИДЕДӘ

Җиләк чәчәк аткан чаклар,
Йөрәккә ут капкан чаклар...
Саубуллаштык мәктәп белән,
Унҗиде яшь иде безгә!

Орлыкларны җил таратты,
Ел артыннан ел санатты...
Тик җыелсак бергә-бергә,
Унҗиде яшь һаман безгә!

Әле дә җиләк чәчәк ата,
Хуш исләрен җәй тарата.
Олыгаймыйк бер дә, бер дә.
Унҗиде яшь булсын безгә!

Яшьлегебез гөрләп торса,
Эшебездән дөнья уңса.
Без – сөенеч илгә-көнгә!
Унҗиде яшь чөнки безгә...

## САК-СОК

Яшьлек дигән гөлбакчадан
Очып чыктык Сак-Сок сымак.
Без яраткан ал чәчәкләр
Башын иеп калды елап.

Кызарып таң аткан саен
Ерагайды арабыз да.
Шәфәкъ саен әрнү артты
Йөрәктәге ярабызда.

Кара-каршы очып киттек
Сагындырган тарафларга.
Шәфәкъләрдан күчкән моңнар
Көч өстәде канатларга.

Хыял белән янәшәдә
Өмет оча безнең сакта.
Чәчәк атып күтәрме соң
Яшьлек дигән ямьле бакча?

## СИН – ӘКИЯТ

Мин сине уйлап чыгардым
Тик үзем өчен генә.
Ихлас белән ышандым да
Табындым исемеңә.

Мин сине уйлап чыгардым
Сине белмәгән килеш.
Әле һаман шул хыялдан
Башым әйләнеп йөреш.

Мин сине уйлап чыгардым,
Әкияткә буйсындым.
Кайчан күчте чынбарлыкка
Синең күзләр, буй-сының?

Буй җитмәслек рәшә булып
Ник төшемә керәсең?
Сүнеп барган учагыма
Тагын ялкын өрәсең?

## ДУЛКЫНЛАНАМ?

Дулкынланам? Сиңа гына
Тоелгандыр шулай.
Тавышыңнан каушар өчен
Сәбәп тә юк болай.

Дулкынланам? Әйтер сүзем
Оныттырдың кебек.
Көтмәгәндә юлыкканга
Калдым, ахры, җебеп.

Дулкынланам? Менә кызык.
Идел кебек, имеш.
Язгы җилдән чайпалган чак
Инеш кенә килеш.

Синең тавыш – давыл кебек.
Чайпалмаска өйрәт.
Ахрысы, хак: Идел кебек
Дулкынландым кинәт.

## ҮТЕНЕЧ

Биектән карап сөйләшмә,
Күзләреңне күрмим.
Күздән башка аңлашу юк,
Аңлашмауны сөймим.

Биектән торып сөйләшмә.
Күзеңдәге серне
Күңелеңнең ераклыгы
Төшенергә бирми.

Ерактан торып сөйләшмә,
Зурлыгыңны тойыйм –
Күзләр, аваз, күңел аша
Барысын да сорыйм.

Барысы да тулы булсын,
Шул чагында сөйлә.
Бер-береңне аңламасаң,
Аралашу нигә?

## СЕР

Без дөньяны куабызмы,
Әллә дөньямы – безне?
Йолдыз кебек үттең-киттең,
Камаштырдың да күзне.

Күкләремне нурга төргән
Йолдыз атылган минут
Йөрәгемне ут итсә дә,
Калды җанда сер булып.

Үзем генә белгәнгәдер,
Бер ачы ул, бер татлы.
Газабым да шатлык кебек,
Шатлыгым да газаплы.

## ӘЛЛӘ НИ БУЛДЫ МИҢА

Үзәкләрне өзә торган
Мондый сагыш, мондый моң
Көтмәгәндә каян килде,
Тетрәндереп, шундый соң?

Шомыртлар чәчәк атканда,
Әллә ни булды миңа:
Сыкранып, елап, сагынып
Тартылды күңел сиңа.

Еллар үткәч, язгы таңда,
Хыялда сиңа килдем.
Хисләрем калды җавапсыз,
Оялып башым идем.

## ТАҢ

Төн әле. Күкләрдә агыла
Болытлар, кап-кара кайгыдай.
Бер елый, бер көлә шикелле
Шуларда тирбәлгән ялгыз ай.

Таң инде. Болытлар тарала.
Ай әнә китеп үк югала.
Төннәрне күрмәгән кыз бала
Кояшлы чишмәдән су ала...

## ПАР ЧЫНАЯК КУЙДЫМ...

Кичә генә әле икәү идек...
Бүген менә...
тагын үзем генә.
Бер могҗиза булыр –
кайтыр, диеп,
Пар чынаяк куйдым өстәлемә.

Синең белән минем бәхет кенә
Хушлашудан, очрашудан тора.
Төшләреңә кереп йөдәтермен,
Син кайгырма –
сагына дип юра.

Моңга чумган кичләр
шундый салкын!
Син булмагач, вакыт озак үтә.
Син кайт инде.
Очрашасы иде.
Мине дә бит яңа юллар көтә.

## МИЛӘҮШӘ

Әллә күңел – көмеш көзге?
Шул көзгедән төшмәде гел
Синең сурәт – миләүшә гөл –
Сеңелем төсле зәңгәр күзле.

Әллә күзләр, әллә сүзләр...
Охшаш икән кай ягыбыз?
Беркөн без дә картаербыз,
Үткән яшьлек үзәкне өзәр.

Бер үк ярны сөйгән чаклар...
Искә алыйк көлеп кенә.
Тик нигә соң кинәт кенә
Әче сүзләр әйттең чатнап?

Күңел-күзгә – чәлпәрәмә!
Матур иде синең сурәт.
Яхшылыкка карыйк юрап.
Хуш, миләүшәм, үпкәләмә.

## КӨНДӘШЕМ

Сандугач шикелле сайрыйсың –
Җыр булып серләрең түгелә.
Сөйләмә берни дә, болай да
Бәхетең күзеңнән күренә.

Сандугач шикелле очасың –
Чакыра чәчәкле болының.
Нигә соң эндәшер чамам юк? –
Соп-соры чыпчыктай йомылдым.

Сандугач шикелле сайрыйсың...
Ул сине, тик сине ярата!..
Чыпчыклык хәленнән чыгалмыйм.
Өздереп йөрәгем авырта-а-а.

## ЯЗЛАР ҖИТСӘ

Язлар җитсә, нигә йөрәк
Урыныннан кузгала?
Әйтерсең лә ялкын каба
Пыскып торган кузларга.

Нигә икән җанны ярып
Яшьлегем искә төшә,
Онытылган яшьлек ярым
Яндыра, язлар җитсә?

Нигә кирәк миңа хәзер
Үткәнне уйлап көю?
Бер сөенү, бер көнләшү,
Насыйпсыз ярны сөю?

Үткәндәге мәхәббәтем –
Гомерлек татлы серем.
Аны язлар яңарталар,
Кичер, бүгенге көнем!

## ГИПНОЗ

Күзләр – кояш.
Күзләр – көзге.
Нурлар чагыла күздә.
Тик аңламыйм.
Ник аңламыйм?
Синең күзләрең – үзгә.

Кыймыйлар туры карарга.
Ниләр бар карашыңда?
Күзләрең тиештер кебек
Сүзеңә ярашырга.

Ә сүзләрең, ай, ягымлы!
Ә сүзләрең, ай, татлы!
Тик күрмимен күзләреңдә
Нурлар балкыган чакны.

Яшеренгән караштанмы
Якты балкыш көтәргә?
Күзләр – түбән,
сүзләр – матур...
Тизрәк синнән китәргә!

Офыккача йөгерергә,
Карамый алны-артны!
Мескен йөрәк сихерләнгән –
Татлы сүзләрең яклы...

## ЙОЛДЫЗ ИДЕМ

Мин дә берчак
йолдыз идем.
Ялкыным сиңа күчте.
Күктән җиргә атылдым да
Салкын таш булып төштем.

Бүтәннәргә
нур бирсәң дә,
Үзең ялкынсыз калма!
Мин дә берчак йолдыз идем –
Шулкадәр дөрләп янма.

Кызыксыз бер матдә булдым,
Утымны сиңа биреп.
Мин дә берчак йолдыз идем
Нәкъ менә синең кебек...

## БЕРЕНЧЕ КАР

Җанны дәшеп
янар хисләр учагына,
Беренче кар күбәләктәй оча гына.
«Кыш килә», – дип,
яңа хәбәр китерә дә
Ашкына ул туган җирем
кочагына.

Сөенчегә: «К ияү килә!» –
дип кычкырып,
Авыл буйлап
нәни малай йөгергән күк,
Омтыла җир күкрәгенә
беренче кар,
«Өлгердем бит, өлгердем», –
дип сөенгән күк...

## МӘХӘББӘТЕМ МИКӘН?

Назландырып, ялындырып
Сөйдерүләрем истә.
Килсәң, «нигә килдең» диеп
Көйдерүләрем истә.

Үкенгән чакларым булды,
«Ник киттем» дип аһ орып,
Ялгызыңны ташлап киткәч,
Сагышларга батырып.

Горурлыгым булды микән
«Килмә» дип әйтүләрем?
Мәхәббәтем микән инде
Һаман да көтүләрем?

* * *

Үзгәртте мәхәббәт:
Без хәзер көчле дә,
Матур да инде.
Изгелек иленә
Якын да инде.

Үзгәртте мәхәббәт:
Иң якты хисләрдән
Күңелләр тулы.
Киртәләр – вак нәрсә,
Без горур, без олы!

## ГӨЛЛӘР СЕРЕ

Сөйләшәләр гөлләр, агачлар да...
Тик ишетү безгә язмаган.
Үз-үзебез белән артык мәшгуль,
Без югары, өстен яралган.

Ә гөлләр бит безнең өчен яши,
Ә гөлләр бит безне ишетә!
Чын күңелдән бүләк ителгәне
Чәчәк ата өзгән килеш тә.

Әйтелмичә калган сүзләрне дә
Гөлләр тоя, гөлләр сизенә:
Рәнҗегәндә күңел – безнең өчен
Чәчәкләрнең җаны өзелә.

Ник гөлләрне аңламыйбыз икән? –
Сәбәпләрен әле тапмадым...
Беләсеңме, син китергән гөлләр
Минем өйдә чәчәк атмады...

## ШУЛ ГЫНА

Нурлар, дисең,
балкып яна күзләреңдә,
Шатлык кына очрап тора юлыңда.
Кыен чакта дуслар белән
җиңел миңа,
Шатлыгымның бар сәбәбе –
шул гына.

«Син бәхетле,
елмаясың һәрвакытта»
Дисең менә гаҗәпләнеп тагын да.
«Кайгырмасын дус-ишләрем»
димен дә,
Аһ-зарымны сөйләмим мин –
шул гына.

Күздән яшем тамган иде,
тагын сиздең:
«Нишләп әле күңелеңдә
моң гына?»
Чын бәхетне яулап алу авырлыгын
Уйлап куйдым тирән сулап –
шул гына...

## ЯРАТАМ

Ап-ак карга кемдер берәү
«Яратам» дип язып киткән.
Күз яшьләре хәреф булып
Карга эреп төште микән?

Йөрәгенә хисләр сыймый,
Кайсы егет кызын көткән?
Әллә бер кыз сөюенә
Җавап тапмый йөри микән?

Кар эретер кайнар сүзне
Әллә бергә язганнармы?
Кем белә бит...
Ни әйтсәң дә,
Яшерү кыен яратканны.

## ОЯЛЧАН ЕГЕТ

Үткән саен карыйм тәрәзәңә,
Тәрәзәңдә калсын карашым.
Утың яна, пәрдәләрең ачык,
Үзең менә, үзең кая соң?

Тәрәзәңне юри ачкансыңдыр,
Мин сагынып карап үтсенгә.
Күз карашым гөлләреңдә калсын,
Сиңа тиңләп назлап үпсен дә.

Тәрәзәңә карыйм каерылып,
Йөрәксез ул, диеп көрсенмә.
Мин тартынам, хисем тапсын сине
Тәрәзәңнән ташып керсен дә...

## ҮЗГӘРҮ ЮК

Урыныннан тау купса да,
Кеше үзгәрми, диләр.
Ник шайтаннан иман көтәм
Гомер буе мин юләр?

Күрә торып күрмим берни,
Белә торып алданам.
Тау кузгатыр көчне, ахры,
Үз-үземнән табалмам.

Димәк, таулар күчми калыр,
Шайтан килмәс иманга.
Шул килеш яшәрмен инде,
Үзгәрү юк миңа да.

## ТАҢ АТКАНДА

Менә тагын нурын сибеп,
Казанда ал таң атты.
Кояш нуры тәрәз аша
Чәчтән сыйпап уятты.

Мендәремне, юрганымны
Ут-нурлар урадылар,
Битләремнән үптеләр дә
Йокымны урладылар.

Шулар мине туган якка
Якынайттылар төсле.
Әллә минем сагынудан –
Таңнарда сагыш төсе...

## ТЕЛӘК

Өметләрем чынга ашсын өчен
Миңа бик аз кирәк:
Кайнар хисләремә синнән җавап –
Сөю һәм наз кирәк.

Күгебездә сүнмәс кояш булсын
Ышанычым сиңа.
Серләреңне миңа сөйлә бары –
Күңелеңә җыйма.

Нинди генә болыт капламасын
Гомеребез күген,
Саклап калыйк, зинһар, саклап калыйк
Салават күперен.

## КӨЗГЕ ИРТӘ

Җәйге чәчәк... җәйге күлмәк кигән.
Юка ефәк киеп көзгә кергән.
Шул бер катлы күлмәк чукларына
Салкын яңгыр көмеш тамчы тезгән.

Җәйге чәчәк нигә көзгә кергән?
Җәйне шулай озайтырмын, дигән.
Аны күргән миләш тетрәнүдән
Өнсез калган, кайнар башын игән.

Миләш җылысында ул үсәчәк –
Җәйдән килгән ялгыз кыю чәчәк!
Тик беркатлы – юка күлмәгедәй:
Кар төшәчәк тиздән, кар төшәчәк!

* * *

*Гүзәлгә*

Күңелнең дә була буш чаклары –
Җилләр генә йөри сызгырып:
Аһ, җаныңның ялгыз вакытлары –
Минутларны булмый уздырып.

Күңелнең дә көйсез чагы була,
Үз-үзеңне тиргәп җан туза.
Япа-ялгыз авыр түзүләре
Йөрәкләрең әрнеп ярсуга.

Моңлы чагы була күңелеңнең –
Менә-менә ташып түгелер.
Яраларны вакыт төзәтсә дә,
Үзәкләрең озак өзелер.

Күңелеңнең җырлы чагы була,
Яшәешнең якты чаклары –
Их, сузарга шушы мизгелләрне...
Оча гына гомер чаптары!

## ӘЙ, КЫЗЛАР...

*(Кыз җыры)*

Яратудан шашкан чагым,
Төшемме бу, өнемме?
Әй, кызлар, дим, бәгырьләрем,
Кемгә сөйлим серемне?

Сөйгәнемнең минем өчен
Җаннарын бирер көне.
Сөенечтән балкып йөрим,
Юктыр ла моның сере?

Сөйләр идем дускаема,
Үзәкләрен өзәрмен.
Әй, кызлар, дим, серләремне
Сөйләми дә түзәрмен.

Күрмәс өчен дус кызымның
Күз яше түгүләрен –
Йөрәгемнең януларын
Сиздерми йөрүләрем.

Әй, кызлар, дим, әйтегезче,
Кемгә сөйлим серләрем?
Җаннарыма урын тапмый
Өзгәләнгән көннәрем.

## ЗӘҢГӘР ТОМАН

Нидер көтәм, өмет итәм
Унбиш яшьлек кызлар сыман.
Мин төбәлгән тарафларда
Зәңгәр томан, зәңгәр томан.

Томаннарга уралам да
Алданамын ничә кабат,
Әкияткә ышануны
Күңелле бер эшкә санап.

Зәңгәр томан эчләреннән
Зәңгәр сагыш алып чыгам.
Бирешмимен кайгыларга –
Минем йөрәк шундый чыдам.

Сөенәмен алдансам да,
Ярый үзем алдамадым!
Өзгәләнгән үзәгемне
Ялган белән ялгамадым.

Каралмады хыялдагы
Зәңгәр томан, зәңгәр томан.
Бәхет кенә өмет итәм
Унбиш яшьлек кызлар сыман.

## УЙЛАРЫМДА МИНЕМ – УРМАН...

Уйларымда – урман, урман...
Ямьнәренең сере тирән.
Шул серләрне ачарга дип,
Урманыма кат-кат киләм.

Урман яңа яшәргән чак,
Адым саен зәңгәр чәчәк.
Яшьлегемнең чәчәк чагы,
Әле кайчан күз җитәчәк?

Урманнардан гыйбрәт эзлим
Кызарганда җиләкләре:
Яшь гомерем чәчәк койды –
Җиләкләнде, җиләкләнде...

Сагыш сара күңелемне,
Урманыма күзләр керсә,
Агачларны бер-берсенә
Сыендырып җилләр иссә.

Зифа буйлы миләш сынын
Ышыклаган мәгърур имән.
Шул бәхеткә сокланырга
Урманыма кыш та киләм.

Җилләреннән сыгылмаган
Имәненә башны иям...
Син дә мине ышыклачы –
Шундый сөю көтәм синнән!

## ЧАРАСЫЗ

– Очма утка, очма утка,
Очма утка, тукта!
Күбәләккә – кисәтү ни?
Үз җаным ул юкса!

Ялкын хуҗа минем җанга –
Хет кычкырып ела!
Бу гөнаһсыз гөнаһларны
Ярлыкармы Ходa?

Үз-үземне тирги-тирги
Тилмерәмме юкка?
Чамасызмын. Чарасызмын
Йөрәктәге утка.

Күбәләктәй кыю җаным!
Акыл синнән курка:
– Очма утка, очма утка,
Очма утка, тукта!

## САГЫНУ

Син булмагач, тәрәзәләр моңлы.
Тәрәзәләр – яшьле, күзләр сыман.
Сагышлары көнгә йокмасын дип,
Мин аларга алсу пәрдә корам.

Син булмагач, пәрдәләр дә моңлы.
Шәфәкъ алсулыгы – пәрдәләрдә.
Шатлык өстәсен дип утыртсам да,
Башын игән әнә чәчкәләр дә.

Сине көтеп чиксезлеккә дәшәм
Ятим калган моңлы бүлмәбездән.
Тик дөньяда шул ук сагыш икән –
Томан булып күчә синең эздән.

Юксынудан көчле хисләр бармы –
Дөнья тулган сине сагыну белән.
Моңнарымны көннән яшерсен дип,
Тәрәзәмә ап-ак пәрдә элә м...

## КЫЗ КҮҢЕЛЕ

Син кайтуга һушларыңны алам әле:
Язлар ямен сипкелемә салам әле.
Сине күрсәм, күрмәгәнгә салышам да,
Чакырсаң да, эндәшмичә калам әле.

Күзләремә күксел итеп сөрмә тартам.
Чәчләремне бер җыям да бер таратам.
Сагайтуым, саргайтуым дия күрмә,
Бер ачылам синең алда, бер шаяртам.

Күңелеңә исемемне язам әле.
Үзең кебек, гамьсез китеп барам әле.
Сагынудан син дә шулай саргаерсың...
Хәзергә мин, хәзергә мин янам әле.

## ҖЫРЫМ – СИҢА![*]

*(Җыр)*

Чәчәкләргә сәйләп чыклар
Тезеләләр таң тугач.
Чыклар кабып, илһам алып
Сайрый сары сандугач.

К у ш ы м т а:

Җырым – сиңа, җырым – сиңа,
Тыңлый белеп тыңласаң.
Шул сандугач дип кабул ит,
Мин кабатлап җырласам.

Җанга яңа моңнар өсти
Зәңгәр күкле кичләре.
Сандугач та безнең кебек –
Түгеләдер хисләре.

К у ш ы м т а.

Көмеш кебек көй тарала
Чәчәкләр бәйрәмендә.
Сайрый, сайрый сандугачым
Күңелем җәйләрендә.

К у ш ы м т а:

Җырым – сиңа, җырым – сиңа,
Тыңлый белеп тыңласаң.
Бу җыр, бәлки, тумас иде,
Әгәр дә син булмасаң.

---

* Зиннур Гыйбадуллин көе.

## ҮЗЕ БЕЛӘ...

Кем икәнен үзе белә.
Берни әйтмим, сиздермим.
Үземнең дә сызлап торган
Яраларга тидермим.

Сөйләшәмен көлеп кенә.
Әллә чынлап минме бу,
Йөрәгемнән тамчы-тамчы
Кан тамызып тилмерү?

Кем икәнен үзе белә,
Карамый күзләремә.
Тик мин генә белмим менә
Күпмегә түзәремә.

Өстен булып калам шулай,
Көлә-көлә сөйләшеп.
Җаным җиргә ятып елый,
Җир белән тигезләшеп...

## СИХЕРЧЕ

Мин – сихерче,
мин – сихерче!
Күз тидердем бер парга:
Бәхетләреннән көнләшеп,
Күз сирпеп баккан идем.
Шатлыкларын чәлпәрәмә
Китереп аткан идем...

Мин – сихерче,
мин – сихерче!
Сөеп бактым бер парга:

Мин яратып караганга,
Тормышлары да якты.
Ышанмаган ышанмасын –
Сихер көчле, канатлы...

Бармы тагын сихерчеләр?
Кемнәрнең күзе кара?

Мәңге бетмәс сихер белән
Үземә кем карады?
Гомер буе сызланырмын –
Аһ, йөрәгем яралы...

## КАЙТЫРСЫҢ...

Сукбайлыкка чыктыңмы?
Оттырдыңмы, оттыңмы?

Арандагы ат идеңме?
Ирек сиңа ят идеме?

Тезгенеңне чиштеңме?
Җилләр булып истеңме?

Кояшка үрелдеңме?
Нурга әверелдеңме?

Чәчәкләргә кундыңмы?
Үзең чәчәк булдыңмы?

Асылыңа кайтырсың.
Оттырырсың, отарсың...

## НӘСЫЙХӘТ

*(Шаяру)*

Нинди назлы син, песием,
Нинди матур күзләрең.
Тик ирәймә, төннәр буе
Кайтмый йөрмә, юләрем.

Син бит минем юанычым,
Синнән башка күңелсез.
Егетмен дип батырайма,
Песи кызлары юньсез.

Көтмәгәндә, сүз берләшеп,
Кыйнап куярлар әле.
Уйламастан, дәрәҗәңне
Шулай җуярлар әле.

Йә күселәр тешләр инде,
Кичә дә кич кайтмадың.
Тормыш бит ул бик катлаулы,
Төнлә йөрмә, аппагым.

## КАРГА БУРАНЫ

Җил сызгыра. Тәрәзәмне
Ярсый-ярсый кага буран.
Рухым белән язда идем,
Кышны ничек узыйм урап?

Кояш нурын күрсен диеп
Тараттым да чәчләремне,
Ак бураннар күмеп китте...
Назлы җаным нишләр инде?

Күзләремне бәйләмә, кыш,
Коштай очам язга таба.
Бу бит – карга бураннары,
Күңелемә минем кага.

Бу бит – карга бураннары!..

## ЮГЫЙСӘ...

Нинди күзләр,
нинди тирән караш! –
Сөйләми дә серең сыярлык.
Керфек какмый
карап торам да мин –
Күзләрен яшерә оялып.

Андагы наз, анда юмакайлык!
Һич бетмәгән нинди иркәлек! –
Чама белү кирәктер бит, – димен,
Әрләгәндә үзен үртәлеп.

Әмма тугры! Эштән көтеп ала,
Алларыма чыга көн саен.
Шундый иркә, куштан яралмаса,
Яши алмас иде, мөгаен.

Яраттыра үзен, кайгырттыра,
Сырпалана, көннәр туды исә.
Бирсә биргән Ходай хәйләне дә! –
Песи генә бит ул югыйсә...

## СӨЕНЕЧКӘ

Йолдыз атылган чагында,
Кеше үлде, димә.
Йөрәккә йөрәк тартыла,
Мәхәббәтең килә.

Коеп-коеп яңгыр яуса,
Күңелсез соң, димә.
Яңгыр белән аралашып,
Җиргә муллык иңә.

Көзен яфрак саргайганда,
Сагыштан ул, димә.
Кояш төсле яфрак булып,
Сөенечең килә.

## МИНСЕЗ ДӘ...

Ул күптән бит мине
Онытты, диярсең
Һәм бүтән берәүне
Өзелеп сөярсең.

Бакчада бөреләр
Кояшка үрелер.
Без йөргән юллардан
Гөрләвек йөгерер.

Бер ямьле бакчада
Сине ят яр көтәр.
Керфегең очына
Шук тамчы – наз төшәр.

Ул тамчы мин инде.
Торырмын аз гына.
Дөньяң, дип, минсез дә
Яз гына, наз гына...

## БӘРӘННӘР ҺӘМ АДӘМНӘР

Сарык йоны алучының
Күз иярми кулына:
Әнкә сарык ярты еллык
Йон «тун»ыннан арына.

Арына да бәрәннәре
Янына китә чабып.
Алары да әнкәләрен
Барыбер ала танып.

Кайчакта ярый безгә дә
Ияру шул үрнәккә:
Яшәүнең түгел хикмәте
Яңа кием, күлмәктә.

Күпме генә көязләнмик,
Көзгедән карый-карый,
Күзебезгә карау белән,
Кешеләр безне таный.

## ОПТИМИСТИК ШИГЫРЬ

Сарафан сатып йөриләр.
Аны кияр җәй бармы?
Кояш көтеп үткәрәбез
Яңгыр койган айларны.

Белми кояш көткәнне дә,
Туктамый яңгыр ява.
Күңелләре җәйдәгеләр
Сарафан сатып ала.

Кемгәдер көз, кемгәдер җәй –
Яумаса ни, яуса ни?
Булсын гына! – яңгыр итеп
И сибәләр акчаны.

Сарафан сатып йөриләр.
Алучысы бер олау!
Иртәгәдән чыгар кояш.
Явып кал син, яңгыр, яу!

Сарафан алучыларны
Болыт та күрә инде:
Өметләрне алдау оят –
Офыкка чигә инде.

# *V. Жыр эзлим*

## ЕГЕТ БУЛМЫЙК ӘЛЕ

«Егетләрчә» дигән мактау сүзе,
Миңа калса, чыкты модадан.
«Егетсең!» –
дип хупласалар кинәт,
Кызлар кебек никтер кызарам.

Егет булмыйк әле, хатын-кызлар.
Анда – ваклык, әчү, гайбәте...
Тел чарлыйлар
хатын-кызны сүгеп –
Егетләрнең шулмы гайрәте?

Ходай биргән ирлегеннән башка
Горурланыр сәбәп калмагач,
Хатыннардан көлеп ләззәт ала
Ир дигәнең – шулай ярагач.

Бик күпләрен,
пирчәткәмне ташлап,
Дәшәр идем атыш-дуэльгә.
Тик шикләнәм, йөзен яшермичә,
Каршы чыгар икән кем генә?

Егет булмыйк әле, хатын-кызлар.
Өстен калыйк мондый ирлектән.
Ходай биргән хатын-кызлык ямен
Саклап яшик җирдә ничек тә.
Егет булмыйк әле,
хатын-кызлар...

## ХИКМӘТ

«Хөкүмәтнең исе китсен», –
Дия иде бер танышым
Мактанып йөргән кешегә,
Чуалтып фикер агышын.

Мактанчыгы, ялганчысы
Очрап тора – нинди хикмәт!
«Хөкүмәтнең исе китсен!» –
Дип әйтәсе килә ипләп.

Тик шунысы: бу сүзләргә
Кайсысының исе китәр?
Әүвәлгедән дә арттырып,
Үз шөгылен дәвам итәр.

Мактанчыкның, ялганчының,
Хәтта бурның почеты зур.
Фәрештә сыман кылансаң,
Үзең генә булырсың хур.

Чиктән узган азгыннарга
Кинаяләр барып җитми.
Чөнки ниләр кыланса да,
Хөкүмәтнең исе китми.

Хөкүмәтнең исе китми!

## ТАШ КАЛАГА КЕМ БАШ КАЛА

– Таш калага кем баш кала? –
Сөрән салды кем башлап?
Җәлт! – җыелды бала-чага,
Чаңгы-чанасын ташлап.

Таш калага кем баш кала?
Таш каласы – кар тавы.
Ава-түнә үрмәлиләр,
Тарта-тарта танауны.

Таш каласы, ай-һай, биек,
Юлдаш юк менүчегә.
Үргә үзе менү өчен,
Дуслар дуска үчегә.

Таш каланың итәгендә
Яталар да тәгәрәп,
Өстәгене өстериләр,
Тагын тауга үрмәләп.

Ил башының да урыны
Кар тавыннан киммени?
Кар тузаны туздырганда,
Ил күзгә дә күренми.

Таш калага патша башмы? –
Төшерәбез бәргәләп.
Әллә кемнәр тарткалашып
Кала шунда тәгәрәп.

Ленин башмы? – шап – башына,
Күптән срогы чыккан.
Сталин менгән тау башына –
Кулына мылтык тоткан.

Таш калада калу кыен.
Башлар килә дә китә.
Йә бу башны, йә тегесен
Типкәләп гомер үтә.

Горбач кыйный Сталинны,
Ельцин суга Горбачка.
Таш каладан тузан туза,
Тик бу мәсьәлә – башка.

Таш калага кем баш кала?
Сөрән салалар һаман.
Үрмәлиләр – белсәләр дә
Бер тәгәрисен аннан.

Өстерәшә-тарткалаша
Җимерәләр кар тавын.
Тик бер максат –
Баш булырга!
Алла белә калганын.

## ЯЛТЫРАУ

«Туган җир» дип сыгынганнар
Туган җирен ташлап китә.
«Милләтем» дип сөйләнгәннәр
Милләтенә хыянәт итә.

Эшкә биреп күңелләрен,
Тып-тын гына йөргәннәре –
Туган җире, милләтенең
Энҗеләре, мәрҗәннәре.

Ялтыравык уенчыклар
Камаштыра күзне ныграк.
Чын энҗеләр кабырчыкта,
Чын энҗеләр тыйнаграк.

## ЧӘЙГӘ ЧАКЫРУ

Күчтәнәчең нигә кирәк,
Үзең булмагач янда?
Сый-хөрмәтем өстәл тулы,
Берни юк кебек алда.

Тәм-томсыз да эчә алам
Бер чынаяк чәемне.
Күчтәнәчкә үзең килсәң,
Вакытың җәл идеме?

Мин андый ук әрсез түгел,
Сине кабып, чәй эчмәм.
Син янымда булган чакта,
Су да татлы – чүмечтән!

Күчтәнәч кирәк, дидемме? –
Шаярттым да оныттым.
Сыйланырга утыр, әйдә,
Кызганма биш минутың.

Миндә дә бит шул ук вакыт,
Артыгы бирелмәгән.
Чәйләү өчен бердәнбер шарт –
Күчтәнәч диелмәгән.

Бергә-бергә чәй эчүнең
Күчтәнәчтәме яме?
Моннан соң берни сорамам,
Үзең генә кил, яме!

## ҺАВАСЫЗ...

Мин бит сиңа һава кебек идем,
Хәлең ничек хәзер, һавасыз?
Бардыр дустың,
бардыр сердәшең дә,
Ә һаваның булмый яңасы.

Мин бит сиңа һава кебек кирәк,
Суламыйча ничек яшисең?
Тел тибрәтеп, «кил»
дип дәшәр идең,
Миннән башка, беләм, ятим син.

Үз-үземә зур бәядер, бәлки?
Әллә сиңа шулай ышанам?
Уйны – уйга, җанны җанга ялгап,
Күңелемнән сиңа юл салам.

Тел тибрәтеп үзең чакырмагач,
Синең якка юллар өзек бит.
Үрсәләнеп сөрән салуым бу:
– Мин бит сиңа
һава кебек! – дип.

## ИСЕҢДӘМЕ?

Исеңдәме Казан урамнары,
Күккә ашкан биек-биек йортлар?
Безгә карап бәхет юрагандай,
Күз кысышкан аллы-гөлле утлар?

Икәүләшеп очып уздык бугай
Иксез-чиксез озын урамнарны.
Җаныбызны, җылы өермәдәй,
Бары шатлык, шатлык урап алды.

Исеңдәме, яңгыр яуган иде,
Җитәкләшеп, гөрләвекләр кичтек?
Бөтен Казан карап торган чакта,
Алдыбызга күктән йолдыз төште.

Кулларымны алып кулларыңа,
Йолдыз йөзгән гөрләвектә юдың.
Кулым гына түгел, бөтен тәнем,
Җаным белән садә-чиста булдым.

Исеңдәме болар, исеңдәме?
Дәшмисең һич, димәк, төшенмисең.
Кичер берүк, үзем генә күргән,
Үзем генә белгән төшем ич син!

## СИН КУРЫКМА

Син курыкма
минем шигырьләрдән:
Алар синнән берни өмет итми.
Җаным бары:
«Дөнья ваклыгыннан
Тик беразга мине азат ит», – ди.

Мин яшерәм арып-талган җанны,
Кайнар хисләремә төреп-төреп.
Ямьсезлектән ямьнәр эзләштереп,
Бәгыремне парә-парә телеп.

Мин яшерәм яшьле күзләремне
«Яратам» дип язган шигыремдә,
Кешеләре бер кадерсез булган
Тоташ борчу, мөтәгамь иленда.

Һичьюгында, сөйгән, сөелгәннәр
Бәхет тапмасмы дип җир йөзендә,
Сиңа булган хисләремне сөйлим
Янып-көеп язган шигыремдә.

Син курыкма минем хисләремнән,
Минем сөю учак булып янсын.
Өшегәннәр, күшеккәннәр, килеп,
Учагымнан җылы таба алсын.

Син курыкма минем сөюемнән...

## СИН

Сабыр савытларым тулган чакта
Чайпалдырмый
тотып торучы – син.
Иләсләнеп, хисем кузгалганда,
Гаеп итми йотып торучы син.

Эндәшмичә газап өстәүчем дә –
Тилмерепләр синнән сүз көткәндә.
Кытай диварыдай – ышанычлым.
Суга таянгандай – шик-шөбһәм дә.

Ни могҗиза:
тоташ каршылык син...
Шул килеш тә –
җанның иң түрендә!
Мин таянам сиңа таш дивар дип:
Рисвай итмә авып ил күзендә.

Һәм битараф кына була күрмә,
Тап үзеңдә сыендырыр көчне,
Үзең кебек тоташ кытыршылык,
Каршылыктан торган
минем хисне.

## ГАШЫЙК

Кулларыңны куйчы маңгаема,
Сизәсеңме, ничек яна башым?
Күзләреңә кереп адаштыммы,
Канатланып күкләргәме аштым?

Рухым бүген әллә кайда йөри…
Кайнар башым –
синең алларыңда.
Күзләреңә карап талпындым да
Былбыл булдым сөю аланында.

Сүзләр артык, йөрәк кенә сөйли.
Хыялый мин синең яннарыңда.
Их, шул килеш җырга әйләнергә,
Әкияткә барып ялганырга!

Хәйләсездер бу хыялый сөю,
Мөмкин түгел хистә алданырга!..
Мин тезләнеп
сәҗдә кылам бүген
Мәхәббәтнең ихлас ялганына…

* * *

Мне нравится, что я
больна не Вами...

*М. Цветаева*

Сезнең күзләрегез ошый миңа:
Йә бик моңлы, йә бик шаян алар.
Көләсез дә, йөзегезне нурлап,
Чокырчыклар уйнап шаяралар.

Шаяртуларыгыз ошый миңа –
Аңлаучылар бармы
миннән башка?..
Күңел генә гел яшьлектә кала,
Бәсләр төшә юкса безнең башка.

Җырлавыгыз бик тә ошый миңа:
«Герман көйләре»ндә
күпме сагыш!
Сез җырчы да түгелдер дә, бәлки,
Ошый миңа, ошый Сезнең тавыш.

Хисләремнең иң-иң ихласлары –
Сезгә багышланган җырым шушы.
Хыялымда гына калыр өчен
Башканыкы булуыгыз ошый!

## БӘЛКИ...

Җилләр безгә гел-гел каршы исә,
Йолдызнамә бәхет юрамый...
Борынгыдан килә: беркем әле
Язмышларны кире боралмый.

Бер-беренә каршы агып барган
Елгалардай яши бирәбез.
Без – арада чиксез бушлык яткан
Ике полюс инде – беләбез.

Җәйге таңда җирдән күтәрелгән
Томан булып икәү берләшсәк –
Бәлки әле, яр таллары бездән
Мизгелләрне санап көнләшмәс?

Гасырлардан бирле ике якка
Язмыш-ярдан узмый акканга –
Мәхрүм итмәс, бәлки,
каршы җилләр
Биеклеккә ашкан чаклардан?

Яр буенда ак томаннан оеп
Йокласыннар көнче таллыклар...
Мәңгелектән мизгел генә бит бу! –
Язмыш безне, бәлки, ярлыкар?

## ЙОЛДЫЗ НУРЫ

Сабырлыклар җитсә, бу кадәр үк
Өзгәләнмәс идем ләбаса.
Синең өчен – уен... чираттагы...
Минем өчен – әрнү дә хафа.

Күзләреңдә – ят йолдызлар нуры.
Хыялларым тиңләп канатка,
Очар идем – шул йолдызлар җиле
Канатларны сугып каната.

Әллә уйлап, әллә уйнап шунда,
Фәрештәгә тиңләп юатма!
Араларда хәтта гадиләр дә
Кичәлмәслек озын юл ята:

Утлы йолдыз юлы...
Язмышларны
Юл яздырып сыный, уйната.
Сиңа кызык: күзләреңдә – ләззәт!
Минем җанда бетмәс моң ята.

## ЧЫҢ

Якын килмә миңа –
мин бәллүрдән.
Якын килмә – хәзер уалам.
Чәчеләм дә, челпәрәмә килеп,
Күз алдыңда бетәм, югалам.

Якын килмә миңа: синең килү –
Сил ташканда купкан җил кебек.
Бәллүр йөрәк калтыранган саен,
Ватылырга тора җилкенеп!

Ватылырга торам, кызган мине:
Якын килмә, саксыз кагылма
Синең силдән чак-чак исән калган
Чыңлап торган бәллүр җаныма.

Минем язмыш кыл өстендә бугай.
Соңгы чикне юкса тоясың...
Синең дөньяң гаҗиз торыр бертын
Бер чыңлаудан бары –
чың, чың, чың!..

## КОРЪӘН АРАСЫНДА КАЛГАН ХАТ

Хәзер инде могҗизаны
күрдегезме?
Бездән өстен язмышларга
көндегезме?
Хыял кала хыял килеш –
белдегезме?
Гамәлләргә тик бер Алла
хуҗа булыр.

Учак булып
күп тапкырлар яндыгызмы?
Очкыннарга сулыш өреп
ардыгызмы?
Яна-яна кайнар көлгә
калдыгызмы?
Яңа уттан тик бер Алла
саклап торыр.
Язмыш саклый ялгышлардан –
тойдыгызмы?
Хәтерегезгә гомерлеккә
уйдыгызмы?
Гөнаһлы уй,
буш хыялны куйдыгызмы?
Сездән мине тик бер Аллам
яклап торыр.
Бәхет юрап йолдызнамә
ачтыгызмы?
Уегызда үткәннәрдән
качтыгызмы?
Былбыл булып һаваларга
аштыгызмы?
... Раббым Аллам! Ярлыкагыл,
ярлыкагыл...

## МИНЕМ ИСЕМ

Китәрсең дә югалырсың,
Күңел кырында бер гөл...

*(Усал шаярту)*

Китәрмен дә югалырмын,
Төшмәм хәтта исегезгә.
Телгә керсә, төртелерсез
Минем кыен исемемә.

Һәр сүзегез тиеш чакта
Энҗе кебек тезелергә,
Ачуыгыз килер микән
Көрмәкләнгән телегезгә?

Таң гөлләре әзер чакта
Сезнең өчен өзелергә –
Минем исем... сезнең телне
Буйсындырмас үзегезгә.

Гөл чугыннан тамган чыкны
Киптерергә күзегездән
Кояш булып балкучыны
Сизмәссез дә күгегездә.

Күңел-кырда гөлләр чиксез...
Тезгән чакта түшегезгә –
Китәрмен дә югалырмын,
Кермәм хәтта төшегезгә!

## СОҢГЫ ЧАКЫРУ

Син ай булсаң,
мин – кояш...

Мин ашыктым һаман,
син соңладың.
Син соңладың никтер гомер буе.
Ятлар читтән бәя биргән булды:
Бер-берендә, дип, боларның уе.

Читтән безгә бәхет юрадылар,
Тик безгә ул тоттырмады һаман.
Син, ай булып,
кичен калыккансың,
Ә мин яндым, кояш булып,
таңнан.

Хыял аша бергә булганда да,
Көннәр аяз икән, төннәр якты.
Мин ашыксам, син соңлама инде.
Таң атканда әллә йоклар чакмы?

Сүрәнлегең айдан күчкәндер шул,
Ут-ялкыннар миңа – таңнардан.
Мин соңгы кат, бәлки,
эндәшәмдер,
Син: «Соңламам, – диген, –
соңламам!»

## ЯНМЫЙ УЧАК

Янмый учак, янмый учак.
Төтен генә бөркелә.
Әчесеннән күзләремне
Ачалмыйча интегәм.

Пыскый учак, пыскый учак –
Төтен исе чәчемдә.
Җил иссә дә ялкынланмый,
Көле генә чәчелә.

Төтен әчеседәй кисеп,
Тамагыма бөялә
Синең исем... Калдың ничек
Үткән утлы көннәрдә?

Учакларың исән микән?
Бардыр сиңа тиңнәр дә...
Синле көннәр сагыш булып
Баса минем иңнәргә.

Шатлык – парлы,
сагыш – сыңар.
Учак янмый интегә.
Өмет тулы күңелемә
Төтен генә бөркелә.

## КҮҢЕЛ ГЕНӘ БУШАП КАЛДЫ

Күрер күзне күрмәс итәр
Сихер бар микән әллә?
Кабындыммы учак булып
Син үтеп киткән мәлдә?

Син йөземә караганга
Яшердемме күзләрем?
Төшләремдә адаштың да
Саташтырдың төннәрен.

Өметләнеп көтмәсәм дә,
Хыялыма тимәдем.
Дөньямда син булган өчен
Якты иде көннәрем.

Вакыт үтте, әфьюн сыман
Сихер китте тәнемнән:
Буш хыялга башны иеп,
Ничек төссезләнелгән!

Әле ярый, айныдым да
Чыктым көлке хәлемнән.
Күңел генә бушап калды,
Бушап... яшьлек яменнән.

## ӘБИЛӘР ЧУАГЫ

Ява яфрак яңгырлары –
Кызыл-сары, кызыл-сары.
Кызыл-сары күбәләк тә
Яфрак булып оча тагы.

Әйтерсең лә маскарад бу,
Карагызчы керфек сирпеп –
Яфракмы соң, күбәләкме,
Канатларын куя җилпеп?

Кызыл-сары, кызыл-сары,
Бердәй матур икесе дә.
Кунсын әле чәчегезгә,
Сокланыгыз көз төсенә.

Ява яфрак яңгырлары,
Тылсымыннан торам оеп.
Кызыл-сары тамчыларга
Учларымны ачып куеп.

## БАЯН

Онытылып көлгән чагым иде.
Бу сагышлар иңде кинәт каян?
Миңа карап, әчтән сызды бугай
Безнең белән гомер иткән баян.

Вакыт – табиб,
дәваламый калмас.
Йомылыр әле син ясаган ярам.
Ләкин калыр гарип җанлы булып
Безнең белән гомер иткән баян.

Синең белән китсә ярты җаны,
Ярты җаны аның миндә калган.
Чит күзләргә бөтен кебек үзе –
Безнең белән гомер иткән баян.

Безнең яшьлек моңнарына тугры...
Бернигә дә алмаштыра алмам. –
Син онытма, хет син, – дия кебек
Безнең белән гомер иткән баян.

## АВТОПОРТРЕТ

*(Шаяру)*

Серле дөнья эзләп адаштыммы?
Барган саен – куе чытырман.
Көнчел белән биеклеккә ашам,
Төп башына килеп утырам.

Үз-үземнән көләм ачы итеп:
– Әйдә инде, юлың ачыкла!..
Кайчагында, юкны эзли-эзли,
Әвереләм метер карчыкка.

Кычкырынам, бәйләнәмен юкка:
Анда гаеп, монда кыек бар...
Аңа карап, чикми чытырманым,
Баш очымнан китми болытлар.

Серле дөнья эзлим: а-у, а-у!
Яктылыкка, имеш, юл тотам...
Ә каршыма, чытырманнар аша,
Шүрәлеләр чыгып куркыта.

## АККОШ КҮЛЕ

*Гүзәлгә*

Сагынып кайтыр күле була
аккошларның,
Ымсындырып яз чакырса
туган якка.
Зәңгәр күле ихлас сөю бүләк итәр,
Аккошкае сәлам биреп
канат какса.

Күл-көзгенең күңелкәе
хистән тулы:
Хыялында бер дә китмәс
аккошы бар.
Шуңа күрә төнбоеклы күзләреңдә
Мәңге сүнмәс илаһилык
балкышы бар.

Чынбарлыкта һәм хыялда –
ике аккош...
Их, икесе бер җан булып
канат какса!
Күл бу хакта уйларга да
җөрьәт итми,
Аккош кунгач,
чайпала тик алка-алка...

## ЮАТУ

*Эльмирага*

Боегып калган кара җирне
Күмеп китсен ап-ак буран.
Шикләреңне читкә ташлап,
Син дә акка, акка уран.

Бу дөньяны, хәрәкәтне,
Юк, без уйлап чыгармаган!
Ул бүген дә төрле төсле,
Кичә дә нәкъ шулай булган.

Иртәгә дә шулай булыр.
Ә син бүген акка уран!
Бу үзе бер фәлсәфә бит:
Юккамы син кышта туган?

Ап-ак кышта тугансың син,
Ә дөньябыз гөлләр төсле!
Барысын сөеп кабул итик,
Читкә ташлап төрле шикне.

## КӨЗ

Яратам дип нигә көчәнәсең?
Күптән сүнде учакларның уты.
Алмагачлар яфракларын койды,
Кәүсәләрдә туңды яшәү суты.

Алма-бакча сөю хатирәсен
Сары яфрак итеп җиргә түши.
Мин, күшегеп, шәлгә төренәмен,
Әллә тәнем, әллә җаным өши.

Җылытмакчы булып үреләсең,
Сизмисеңме җаным үртәлгәнен?
Бер үк учак янмый ике тапкыр,
Онытылды сине көткәннәрем.

Мин көткәндә
син кайларда идең?
Яратам дип көчәнәсең хәзер...
Бер кошмы соң
ялгыш сайрап куйды? –
Яз көннәрен искә төшерәдер...

## КЫШКЫ ЧИШМӘ

Ап-ак карлар зәңгәр күләгәле,
Челтәр шәлдән яшел чыршылар...
Күңел тагын бер кат иләсләнер,
Көмеш чишмә булып чылтырар.

Ап-ак карга эзләр сала-сала,
Язга таба атлап китәрмен.
Көмеш чишмәм эретер салкыннарын
Зәңгәр күләгәле көртләрнең.

Бөтерелеп аккан зәңгәр бозда
Саубуллашкан кебек ут янар...
Китми тор, кыш!
Минем чишмәм әле
Кар астыннан, бәлки, юл табар.

## БӘСЛЕ ТЕЛӘК

Урманнарга керик бәсләр коеп,
Тормасыннар йоклагандай оеп.
«Яңа е-ел!» – дип
аваз салыр җилләр,
Һәм болытлар
йолдыз-карын сибәр...
Җем-җем итәр безнең киемнәрдә!
Тылсым көче бардыр бу көннәрдә –
Уй-хисләрнең иң сафлары калыр,
Киләчәккә безне алып барыр.
Яңа елга бары шундый теләк!
Күрәсезме, бүләкләрен төяп,
Кыш бабай да инде юлга чыкты:
Агачлардан коела ап-ак сыкы.

## ҮКЕНЕЧ

*Рөстәм Мөхәммәтҗановка*

Язгы бакча, кошлар сайрый,
Чәчәкләр – түтәл-түтәл...
Кемнедер көтә зарыгып,
Ак урындык, ак өстәл.

Фәрештәдәй бер асыл зат
Ашыкмый гына килер.
Үзен дәшкән фоторәссам
Күптән монда дип белер.

Әмма рәссам бәйрәм итәр,
Эш турында онытыр.
Шәраб тулы чәркәләре
Шаярыр чылтыр-чылтыр.

Фәрештәдәй асыл заты
Көтәр-көтәр дә китәр.
Төн челтәрен ябынып йоклар
Ак урындык, ак өстәл.

Өр-яңадан туар оста
Иртәгә таң атканда.
Фотоаппаратын асар да
Чабар теге бакчага.

– Илле яшем тулды, – диеп
Акланыр чәчәкләргә...
Тик «кил» диеп фәрештәгә
Ничек кабат дәшәргә?

## СУ БУЕНДА

Комлы ярга дулкыннарын кагып,
Безнең белән елга шаяра.
Дулкын-дулкын еллар
кергән инде
Синең белән минем арага.

Еллар гына нәрсә? Гомер, гомер...
Сүтәргәме хәтер йомгагын?
Сулар ага, яңа дулкын юа
Тын ярларның кайнар комнарын.

Безнең ярлар иде, безнең елга.
Башка сулар хәзер, башка ком...
Яшьлегебез исән әле җанда,
Күпме сулар гөрләп акмасын.

Агымсуга салыйк серебезне,
Бар дөньяга әйдә таратсын:
Ярын һичкем ятка калдырмасын,
Бары үзе, үзе яратсын!

## ТУКТАЛЫШ

Бар сәгатьләр туктап калды
Без бәхетле минутта.
Сулыш алмый торды дөнья –
Талды сихри тынлыкка.

Бар сәгатьләр туктап калды,
Изге мәлне тоткарлап.
Бер тавышсыз канат кагып,
Очып узды акчарлак.

Тавышсыз гына чайпалып,
Дулкын какты ярларга.
Безнең йөрәк тибеше тик
Китте әллә кайларга.

Әллә кайларда яңгырап,
Кайтаваз булып кайтты.
Туктаган мизгелне узып,
Алсуланып таң атты.

Тынып калган серләр илен
Кузгатты безнең йөрәк!..
Тек-тек итеп, тек-тек итеп
Йөри башлады сәгать...

## СИН КИТКӘЧ

Тәрәзәмне ачтың – җил уйнады.
Тәрәзәмне ачтың – җил керде.
Йөземдәге учакларга өрде.
Йөрәгемә ташып сил керде.

Йөрәгемне агызып ла китте...
Тәрәзәмне яптың – нишләдең?
Тәрәзәмнән кояш нуры керде.
Кояш нуры булып төшмәдең.

Йөзләремдә – учак урыннары...
Сизәм, сизәм җанны өткәнне.
Тәрәзәдән күзем алып булмый:
Карап торам синең киткәнне.

## КЕМ ӘЙТКӘН?

Мәхәббәт – бәхет, дип,
Кем әйткән һәм кайчан?
Ярату – шатлык, дип,
Яңалык кем ачкан?

Кем әйткән, ни өчен?
Нигә соң алдашкан?
Мин дә бит яратам –
Чыгалмыйм газаптан.

Зарымны тырышам
Йөрәккә бикләргә.
Серемне сөйләргә
Дустым юк, нишләргә?

Каршылык корганнар
Безнең һәр адымга.
Күпмегә куярлар
Киртәләр тагын да?

Ул да бит ярата,
Чыгалмый газаптан –
Ярату рәхәт, дип,
Кем миңа алдашкан?

## ХУШ!

Әгәр сине туйдырганмын икән,
Сәбәп эзләп йөрмә китәреңә.
Гомерләрем зая үтә, дисәң,
Каршы төшмәм синең шикләреңә.

Үз җаныңны,
минем җанны кыйнап,
Сәбәп кенә эзләп йөри күрмә.
Курыкканым:
син кош булсаң әгәр,
Булмасамчы сиңа читлек-төрмә.

Кызганулар белән түбәнсетмә,
Бар сәбәпләр –
дөреслектән мескен.
Хакыйкатьне кабул итәр йөрәк,
Ялган гына –
хәнҗәрләрдән үткен.

Чын дөресен күтәрермен, димен,
Ялган хәнҗәреннән исән калмам.
Оч еракка, кош йөрәкле дустым...
Ярлыкасын сине газиз Аллам!

## ТЫНГЫЛЫК БИР!

Тынгылык бир, тынгылык бир,
Үзең дә бер тынычлан.
Беләсең бит – бу йөрәкләр
Коелмаган корычтан.

Тынгылык бир, тынгылык бир,
Куләгәңне юлдан ал.
Икәү йөргән аланнарны
Күмеп китсен бураннар.

Икәү бергә кичкән җәйнең
Яктылыгын уйламам:
Кояш төшкән аланда да
Кара шәүлә уйнаган.

Монда безнең кәккүкләрнең
Йөрәкләре ярылган.
Бер могҗиза – тынгы көтәм
Килер кышның карыннан.

Тынгылык бир, тынгылык тап –
Бураннарда югал да!
Йөрәкләр шул – кәккүкләрчә...
Корыч түгел алай да.

Югал, зинһар! Ә мин, ахры,
Шул аланнан айрылмам:
Монда безнең кәккүкләрнең,
Ел санаган кәккүкләрнең,
Бәхет көткән кәккүкләрнең
Йөрәкләре ярылган бит,
Йөрәкләре ярылган...

* * *

Рәхәт лә ул акыл белән
Фикер йөртү,
Чит-ятларны үз кысаңа
Төртеп кертү.

Янәсе, мин алай булмам,
Болай булмам,
Иләсләнеп беркайчан да
Гөнаһ кылмам.

Башкаларның ялгышлары
Күренә шул.
Гаебенә, гайбәтенә
Керелә шул.

... Язмыш җиле уңга кагар,
Сулга кагар –
Зиһен сүнәр, йөрәгеңә
Утлар кабар.

Зилзиләдән сукыр калыр
Күзләрең дә...
Бар ышаныч дөрләп торган
Йөрәгеңдә...

И беркатлы аек акыл!
Сынап кара:
Иләсләнү хәлләренә
Чыдап кара!

## ТУЙЛАР ИЛӘ УЙЛАР...

Җиде диңгез кичәсең,
Каф тауларын үтәсең,
Әкиятләрдә язылган
Батырларга ияреп.

Тарактан урман үсә,
Күл булып көзге төшә.
Хәсрәтләрдән көясең,
Каеннарга сөялеп.

Күтәрелеп тәхеткә,
Ирешәсең бәхеткә,
Кырык көн туй итәсең,
Хан кызына өйләнеп.

Әкият туйда бетә.
Уй чынбарлыкка күчә:
Туең узгач ул яшәү –
Җәфа күреп, чиләнеп!

Җиде диңгез кичәсе,
Гомер юлын үтәсе,
Утка-суга төшәсе –
Яшәгәнче көйләнеп...

## АЛТЫН АЛМА БЕЛӘН ХУШЛАШУ

*(Егет сүзе)*

Нәрсә булды? Сине күргән көнне
Йөрәккәем кинәт өзелеп төште.
Мондый халәт илаһи бер өндер,
Йә булмаса артык реаль төшме?

Син кичәнең бер гүзәле идең,
Тик елмаеп миңа дәштең бары.
Бөтерелеп без биегән чакта,
Көнләштеләр егет асыллары.

Бу төш белән өн арасы иде,
Чынбарлыкта булмас андый халәт.
Фәрештәләр, килеп, колагыма
Пышылдады кебек: «Ярат, ярат!»

Яраттыммы? Әллә инде язмыш
Сынадымы безне көлә-көлә?
Утлар сүнгәч, дәртләр сүрелә төшкәч,
Аерылырга язган икән менә.

Араларда гади генә киртә:
Мин туганмын бары синнән соңрак.
Барыр юлны бергә итәр өчен
Безнең ара ерак икән, ерак...

Аклый алмам синең өметләрне,
Мин, күрәсең, әле сары томшык.
Минем белән булмый
тормыш корып,
Биеп кенә була очып-очып.

Синең кебек мин дә газапланам,
Алдый алмыйм ләкин хыялларны.
Теге кичә... шундый ымсындырды,
Өметеңә канат куялмады.

Тиңнәреңне табуыңны теләп,
Башлап үзем синнән китеп барам.
Мин әлегә ачы, яшел бөре...
Бәхетле бул, йә, хуш, алтын алмам...

## БӘЛЛҮР КАСӘ

Озайтмакчы булып төшләремне,
Күзләремне ачмыйм, сине күрсәм.
Сине күргән төшне, юратмыйча,
Күңелемдә генә саклап йөртәм.

Бар тылсымы сүнәр, сүрелер дип,
Телгә алмыйм якты төшләремне.
Белмисең шул өндә синнән качып,
Төшләремдә өзелеп көткәнемне.

Күзем йомсам, синең шәүләң килә,
Бәгыремне парә-парә телеп.
Саксыз тиеп уалтудан куркам,
Буш хыялым бәллүр касә кебек.

## МОҢСУ ТАБЫШ

– Вакытлыча бу хис, үтәр, –
дидем,
Тыштан сине шулай юаттым.
Эчтән яндым, ә син кабатладың:
– Мин югалттым сине,
югалттым!..

Керфек какмый август төне үтте,
Өскә яуды йолдыз яңгыры,
Бөрлегәннәр тамды өзелеп-өзелеп,
Сабакларның сынгач сабыры.

– Мин югалттым сине,
мин югалттым...
Сискәндерден нигә җанымны?
Томырылып чапкан бу гомердә
Очрашырга мизгел табылды!

Күзләреңдә – август моңсулыгы,
Калырсыңмы шулай исемдә?
Мин язмышка рәхмәт укыйм әле
Табыштырган бер кич өчен дә...

## АЕРЫЛАСЫ КИЛМИ, ДИСЕҢ...

Күз алдымда – күз яшьләрең,
Йомшаклыкмы ир-ат өчен?
Искән җилдәй исте вакыт,
Аерыласы килми, дисең.

Сүзләр түгел, күзләр генә,
Җырлар гына калды истә.
Иренеңнән үрелеп үпте
Якты йолдыз айлы кичтә.

– Киттек-киттек, – дип үртәде
Тәгәрмәчләр, җанга тиеп.
Үзгәрмәслек кануннар бар –
Саубуллаштык башны иеп.

Сине үпкән йолдыздан да
Китеп барам, көнли-көнли.
Тәкъдир безгәниләр язган?
Аерыласы килми, килми!

## СИН АЗАТ МИННӘН*

*(Җыр)*

Ике учак арасында
Айкалу – нинди газап!
Шуны аңлап, мин бүгеннән
Коткарам сине үземнән –
Син азат миннән, азат!

Кыйнама бүтән җаныңны,
Миңа бурычлы санап.
Бүләк итәм шаулы язны,
Бәхетле ит тик бер ярны –
Син азат миннән, азат!

Уттан утка ташланмыйча,
Бердәнбереңне ярат.
Учак кебек мин сүнәрмен,
Юклыгыңа да күнәрмен –
Син азат миннән, азат!

Хисләремне чайпалдырма
Киткәндә, күзгә карап.
Күздән яшьләр тамуы бар,
Тагын китми калуың бар...
Син азат миннән, азат!

* Җәгъфәр Касыймов көе.

## СЕЗДӘ ҺӘМ БЕЗДӘ

Сезнең якта күкләр аяз иде,
Бездә кояш – болыт арасында.
Тик ул көннәр кире кайтмас инде,
Ялварыплар кабат чакырсаң да.

Сездә көннәр җырлы-моңлы иде,
Ап-ак иде урман тирә-якта.
Бездә көннәр сүрән һәм гадәти,
Соры дивар тора безнең сакта.

Сездә тәүлек шундый озын иде, –
Йокламыйча үткәргәнгә төнне.
Ә мин монда кичтән
ятып йоклыйм,
Төшләремдә күрергә дип сине.

Сездә тагын... Сездә –
син бар идең!
Ә биредә – хәтеремдә бары...
Сезнең якның яман ягы да бар –
Син бит анда башка кеше яры.

## МАНДОЛИНАЛЫ КИЧӘ

Мандолина кылларында
Тетрәтерлек моң барын
Белмәгәнмен моңа кадәр,
Исем китеп тыңладым.

Көмеш телле мандолина
Челтерәп көлә кебек.
Җанны күкләргә күтәрә,
Кайнар хисләргә төреп.

Ул арада сагышлардан
Елата зарый-зарый.
Медиаторы биеп йөри,
Кылларын саный-саный.

Парын җуйган былбыл сыман,
Уйнаучысы өзелә.
Көйләренә кучә кебек
Күңлендәге зилзилә.

Ялгыз калган шул үзе дә
Кергән чакта көзенә...
Куанычы, юанычы –
Мандолина тезендә.

Ялгыз калу кемгә җиңел?
Ә ул әнә – күтәрә!
Мандолина кылы аша
Моң-зарларын үткәрә.

Дәшми генә тыңлыйм мин дә
Былбыл телләрен гүя.
Җанымда ниләр кайнавын
Шул мандолина белә!

## ТЕЛЕФОНЛЫ ХЫЯЛ

Чылтырагандыр телефон,
Көткәндер эндәшкәнне,
Калтырагандыр туктаусыз
Мин чыгып киткән мәлне.

Чыккан чагым булгандыр шул,
Телефонның теле юк.
Белсәң иде, синнән хәбәр
Көтмәгән бер көнем юк.

Эзлисеңдер кебек мине,
Телефонны ардырып.
Тик кисешми вакыт кына...
Уза йөрәк яндырып.

Кайтарырдай булам сине,
Тыным белән суырып...
Ниһаять... әллә... телефон?!
Төште җаным убылып –
син түгел...

## АПРЕЛЬ КАРЫ

Ятып ауныйсымы
апрель карларына?
Апрель карларыдай
әллә каралырга?
Кар сулары кебек
язгы җиргә сеңеп,
Умырзая булып
кабат яралырга?

Менә нинди хыял,
менә нинди ярсу!
Кучкыл карны ябынып,
җәйрәп ята басу...
Орлык төшәр көнне
көтәсеме озак,
Кайчан кузгалыр дип,
елгаларда ташу?

«Кайчан яфрак ярам?» –
ди каенда бөре.
Кояш нурларында
бүрткән инде үзе...
Ә син, имеш, шулчак,
күзләреңә китеп,
Ямансулап йөре,
еламсырап йөре.
. . . . . . . . . . . . . . . . . .
Аунар идем, диеп,
апрель карларында...
Юләр хыяллар бер
тиеш таралырга.
Бөре сыман бүрткән
хисләреңне тыеп,
Бик акыллы кеше
булып саналырга.

Менә нинди хыял!
Апрель кары эри...
Ә күзләргә бер дә,
бер дә йокы керми!
Шытып чыгачагын
умырзая булып
Апрель кары әле
төшендә дә күрми...

## ҖЫР ЭЗЛИМ

Җыр эзләп килдем Себергә,
Кайтып барам җыр табып.
Ләкин Себер, салкын Себер
Күңелемне калды алып.

Аңлашылмаган аһәңнәр
Ияреп кайта җанга:
Йоклап яткан йөрәгемне
Уятып, ишек кага.

Дөньямны күмеп илһамга,
Кыңгырау булып чыңлый.
Җыр табып кайтам Себердән,
Җаным һаман җыр сорый.

## ШИГЪРИЯТ

Шигърият – чибәр кыз, диләр,
Фәрештәгә тиңлиләр.
Лира тотып, канат җилпеп
Очкан чагын сөйлиләр.

Сөйлиләр ир-атлар гына,
Сурәтлиләр ир-атлар.
Тагын әле күпме шагыйрь
Шул хыялны кабатлар.

Үзләре шуңа ышаныр...
Гаепләмик, бигайбә.
Шигърият дигән могҗиза
Ир затыннан шулай да.
Ир затының иң дәртлесе,
Серлесе һәм көнчесе,
Сөйгәне өчен көрәштә
Мәкерлесе, үчлесе!

Мәхәббәтен бүлешкәнне
Кичерми шигъри иркә:
Сөеклесен – шагыйрәне –
Йә ялгыз, йә тол итә.

И кызыкай, шигъриятькә
Багышласаң үзеңне,
Гап-гади җир бәхетеннән
Өметеңне өз инде.

Шигърият – көнчел...

## ШИГЪРИ ЧӘЧӘК

*Нәҗибә Сафинага*

Ак миләүшә...
Миңа – шагыйрәдән
Бүләк иде туган көнемә.
Алсу яраннарга иптәш бүген
Шул чәчәкләр тәрәз төбемдә.

Миләүшәләр, серле миләүшәләр
Чәчәк ата кыш та, язын да.
Бүлмәм эчен гөлем нурландырса,
Төннәр буе шигырь языла.

Миләүшәләр үрчи, бүлгәлим дә
Шагыйрьләргә үзем таратам.
Аларга да шигъри гөлләремнең
Илһам нурын алып баралсам...

Мин ышанам:
Күңел нурларыбыз
Зур яктылык булып тоташыр –
Юлындагы чүпне, керне юып,
Язгы ташу сыман бер ташыр!

Ак миләүшә – гади чәчәк түгел,
Юл сабучы җаннан җаннарга.
Насыйп булсын
шигъри туганлыкны
Ак чәчәкләр аша барларга.

## АДАШЛАРЫМ

*Фирүзә Җамалетдинова һәм*
*Фәйрүзә Исмәгыйловага*

Төрле елда, төрле җирдә
Күкләр безне тергезгән дә,
Тиңләгән исем кушканда
Бәхет ташы фирүзәгә.

Шундый кыю исем белән
Җиңел эшме гомер итү,
Бәхет нуры сибәр өчен
Йөрәгеңне күмер итү?

Үзебезгә шул бәхеттән
Күпме тигән, адашларым?
Анык кына беләбезме
Шул турыда, җандашларым?

Шигърияттә юлдашларым,
Исемдәме серләребез?
Яшьләребез төрле-төрле
Һәм яшәгән җирләребез.

Гомер юлы – сынау гына.
Таш яуса да безнең башка,
Ялтырыйбыз хыянәтсез
Тутыкмыйча – асылташ ла!

Бәхет ташы фирүзәгә
Тиңләп, күкләр исем биргән.
Өлешебез – шигырьдәшлек,
Мондый бәхет кемгә тигән?

## МИН СУГЫШТА БУЛДЫМ

Мин сугышта йөрдем әткәй белән,
Әткәй белән җиңү яулаштым.
Волхов сазлыкларын
кичеп чыктым,
Камалышта калып адаштым.

Әсирлекнең тойдым ачыларын,
Юкса каян миндә мондый моң?
Шул хакларда китап укысам да,
Шул турыда кино карасам да,
Җаным белән әрнеп елыймын.

Әткәй белән әсирлектән качтым,
Исән кайттым мин дә сугыштан.
«Мин исән!» дип әткәй сөенгәнгә,
Мин тормышны сөйдем тумыштан.

Сугыш беткәч, Сталиннар киткәч,
Мин туганмын җиргә, мин – дәвам.
Әнкәйсез дә, әткәйсез дә күптән,
Ничә үлгән, ничә яралган!

Мин сугышта йөрдем әткәй белән,
Күрәсезме, әле мин исән!
Тынычлыкка җыр-мәдхия әйтеп,
Язгы җилләр булып мин исәм.

## БӘЙРӘМ

Чәчләремне буяп, бөдрәләттем,
Яңа күлмәк кидем өстемә.
Иренемә шат елмаю «элдем» –
Дус-ишләрем күрсен өченгә.

Көзгеләргә багып, сөрмә тарттым,
Күзләремдә чаткы балкыды.
Мин үземне курчак иттем бүген,
Уйны-гамьне сызып аркылы.

Бусагадан атлап чыктым шулай,
Күргәннәрнең теле бәйләнде.
Бер танышым, иҗекләргә салып:
– Әллә, – диде, –
берәр бәй-рәм-ме?

Әйе, бәйрәм! Минем күңелемдә!
Үз кәефем үзем күтәрдем:
Чәчәге дип тойдым үз-үземне
Тормыш дигән олы түтәлнең.

Кыңгыраудай җиргә иелсәм дә,
Көнбагыштай көнгә баксам да,
Чиге булыр гомер җәйләремнең,
Көзләр керер яшел бакчама.

Әлегә мин җәйләремдә яшим
Һәм беләмен аның китәсен.
Шуңа күрә, яшәвемне данлап,
Килде бүген бәйрәм итәсем.

## АЛИШНЫҢ ӘЙТЕЛМИ КАЛГАН СҮЗЕ

Сибеләчәчем җилләргә лә,
Уем туган илләрдә...
Мондый ачы язмыш биргән
Ходай безгәниләргә?

Кемдер әйтер: идеягә
Гомер корбан итмиләр.
Идеяме? Күңелемә
Якын түгел чит җирләр.

Туган илем – идеяме,
Балаларым, сөйгәнем?
Авылымның сукмаклары –
Яланаяк йөргәнем?

Өмет белән көткәннәрем –
Дусларым, туганнарым?
Мин үлемгә каршы бардым,
Исемдә тотып барын!

Йөрәгемнең иң түрендә
Булды газиз милләтем...
Шул сүрелмәс сөюемә
Дошман кыйммәт түләтте.

Һәммәбездән дә түләтте,
Бер булды серләребез.
Сөйгәннәрнең хакын хаклап,
Корбан – гомерләребез.

Безнең өчен бүтәннәргә
Калдырмадык түләргә.
Шул идея өчен, әйе,
Мөмкин иде үләргә.

Туфрак булсак булырбыз ла
Илдән ерак җирләрдә,
Чиста кайтсын исемебез
Туган-үскән илләргә.

## КАЗАНЫМ

Иделем, Казаным –
Шатлыгым, газабым.
Дулкындай тирбәлер,
Йолдыздай янарым.

Яшьлегем сукмагы,
Гомерем юлыдыр,
Моңнардан яралган
Кызымдыр, улымдыр.

Казаным, Иделем,
Тиңдәше юк илем,
Хыялны чын иткән
Җирләрем син минем.

Казаным, Иделем,
Синдәдер күңелем.
Өметле иртәгәм,
Кадерле бүгенем!

## ДУСТЫМНЫҢ ТУГАН КӨНЕ

Ел саен яшьне саныйбыз,
Туган көннәр җитсә,
Мәктәп, класс һәм парталар
Исебезгә төшсә.

Мәктәп еллары озын да,
Калган гомер кыска.
Математикабыз шулай
Алдашамы юкса?

Бер үк елны ничә төрле
Була икән санап?
Тиздән илле дип офтандың,
Календарьга карап.

Иптәш кызым, ромашкалар
Җыеп килдем менә.
Яшь чакларга кайтып килик
Тик бер көнгә генә.

Ромашкалар хыялдай ак,
Тик уртасы сары.
Илле яшь юк әле безгә,
Кырык тугыз бары!

## ЭЧТӘЛЕК

### I. Гомер – диңгез, төсләр уйный...

Феникс . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Алтын йозак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Кырмыска . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Гамь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Сагынам, дисең... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Китәләр... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Агымсулар болгана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Диңгез . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Һәр икенең берсе... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Безнең җыр! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Кануннар... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Дога . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Шагыйрь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Капка хикәяте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Табышмак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Сау булыгыз, китәм... . . . . . . . . . . . . . . . 16
Яңа ел җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Кабатланмас... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Кышкы тәрәзәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Кешеләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Көмеш тәңкә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Оста . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Тауда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Ирек мәйданы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Сиңа кайттым, Актаныш! . . . . . . . . . . . . 23
Күшегү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Кадерсезлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Ике фәлсәфә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Олы кое . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Гармония . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Пар имән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Төшләремә китәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Песиле тал зары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Оя . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Гомер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Каршылау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
И туган ягым... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Шаукым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Иске өй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Туган көн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38

Дөнья кала... 38
Юк... 39
Күчә комнар... 40
Бу дөньяга шагыйрь тудырып та... 41
Мокытлык 42
Бу заман 42
Сүзгә «мәдхия» 43
Үзгәреш 44
Аһ, балам!.. 45
Рәссам истәлеге 46
Мәктәпкә кайту 47
Җырчы җаны 48
Язу – яну 49
Җиде җил чатында 50
Уйламагыз 51
Узмыш юк 52

**II. Төшләремә керәсең дә...**

Парадокс 54
«Диңгезнең дә яры бар...» 54
Йосыф-Зөләйха 55
Яңгыр җиле 56
Киңәш сорап... 57
Их, әгәр дә... 58
Үртәшү 59
Сорама 59
Әйлән-бәйлән 60
Әллә... 61
Яңгырда 62
Кабатлану 62
Сәер, димә... 63
Ничек яратыйм? 64
Син түгел 65
Әгәр китсәм... 65
Җәл 66
Нәркисләр 67
Тол хатын 68
Күләгә 68
Бик сагынгач 69
Яшь аралаш көлү 70
Күңел-күзге 70
Нигәдер... 71
Гөрләвек 72
Каен җылысы 72

Ярattырасым килә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Очрый гына күрмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Рәхмәт сиңа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Шайтан таягы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Әнкәй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Ак чәчәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
Кыз бала . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Мин – күбәләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
«Без – икебез...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
Язар идем... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
«Кара урман» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
Су өчен генә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
Гөл гомере . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
Эндәшмәвең белән... . . . . . . . . . . . . . . . 83
Хыялый диалог . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Бары түз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
Рәсем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
Очыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
Икәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Кит! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Каршылык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Төен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Дәва . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Ярый әле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Билләһи! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Хушлашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Һәлакәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Яфрак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Ялвару . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
Өзелгән өмет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 95
Очрашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96

**III. Алма бакчасы**

Алма коела . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Кайчандыр ул... . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Ике алма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
Ярты алмам! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100
Алмагач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
Әй, алма бит! . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102

**IV. Яшьлек дәфтәреннән**

Өстенлектә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Унҗидедә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
Сак-Сок . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
Син – әкият . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106

Дулкынланам? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Үтенеч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Сер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Әллә ни булды миңа . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Таң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Пар чынаяк куйдым... . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Миләүшә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Көндәшем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
Язлар җитсә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Гипноз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Йолдыз идем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Беренче кар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Мәхәббәтем микән? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
«Үзгәртте мәхәббәт...» . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Гөлләр сере . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Шул гына . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Яратам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Оялчан егет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Үзгәрү юк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Таң атканда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Теләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Көзге иртә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
«Күңелнең дә була...» . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Әй, кызлар... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Зәңгәр томан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Уйларымда минем – урман... . . . . . . . . . . . . 123
Чарасыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Сагыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Кыз күңеле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Җырым – сиңа! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Үзе белә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Сихерче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
Кайтырсың... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Нәсыйхәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Карга бураны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
Югыйсә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Сөенечкә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Минсез дә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Бәрәннәр һәм адәмнәр . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Оптимистик шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134

### V. Җыр эзлим

Егет булмыйк әле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Хикмәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137

Таш калага кем баш кала . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Ялтырау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Чәйгә чакыру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Һавасыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
Исеңдәме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Син курыкма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Син . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Гашыйк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
«Сезнең күзләрегез...» . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Бәлки... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Йолдыз нуры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Чың . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Коръән арасында калган хат . . . . . . . . . . . . . 150
Минем исем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Соңгы чакыру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Янмый учак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Күңел генә бушап калды . . . . . . . . . . . . . . . 154
Әбиләр чуагы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Баян . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Автопортрет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Аккош күле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
Юату . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Көз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Кышкы чишмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
Бәсле теләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
Үкенеч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Су буенда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Тукталыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Син киткәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Кем әйткән? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Хуш! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Тынгылык бир! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
«Рәхәт лә ул...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Туйлар илә уйлар... . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Алтын алма белән хушлашу . . . . . . . . . . . . . . 169
Бәллүр касә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Моңсу табыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
Аерыласы килми, дисең... . . . . . . . . . . . . . . 172
Син азат миннән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173
Сездә һәм бездә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174
Мандолиналы кичә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
Телефонлы хыял . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Апрель кары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Җыр эзлим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178

Шигърият . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
Шигъри чәчәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
Адашларым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Мин сугышта булдым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Бәйрәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183
Алишның әйтелми калган сүзе . . . . . . . . . . 184
Казаным . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Дустымның туган көне . . . . . . . . . . . . . . . . . 186

Литературно-художественное издание

**Муслимова** Файруза Асгатовна

**ЗОЛОТОЙ ЗАМОК**

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Мөслимова** Фәйрүзә Әсгать кызы

**АЛТЫН ЙОЗАК**

Мөхәррире *Ф.И.Фәтхетдинова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.Н.Мусина*
Корректоры *Г.М.Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 27.07.2009.
Форматы 70×100 1/32. Шартлы басма табагы 7,8.
Тиражы 2000 д. Заказ В-1070.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААЖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.